БУЛМАС, ДИМӘ!

Педагоглар кытлыгын роботлар белән хәл итмәкчеләр

> 5

УКЫМЫШЛЫ ХАЛЫКМЫ?

Татарстанның Милли китапханәсе укылган китаплар буенча нәтиҗә ясады

> 5

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре

> 7

ЯЗ ГАЛӘМӘТЕ

Күкме гөнә әзерләнсәң дә, һәр елны көтмәгәндә килә

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 34 (29194) | Сишәмбе | 19 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

БЕРГӘ БАРАБЫЗ

КИЛӘЧӘГЕБЕЗ ӨЧЕН НИЧЕК ТАВЫШ БИРДЕК?

Көнүзәк вакыйга

Сайладык! Алдагы алты елда ил дилбегәсе кем кулында булачагы билгеле. Ил күләмендә бюллетеньнәрнең 100 процентын эшкәрткәннән соң, Владимир Путинның 87,28 процент тавыш җыйганы ачыкланды. Татарстанда төгәл саннар да билгеле. Гамәлдәге Илбашы өчен республикада яшәүчеләрнең 88,7 проценты тавыш биргән. Илнең яңа тарихында сигезенче тапкыр үткәрелгән Россия Президентын сайлау берьюлы берничә рекордны яңартты.

«Татар-информ»

Россия Үзәк сайлау комиссиясе барлык сайлау беркетмәләрен эшкәртеп бетергәннән соң, алдан алынган нәтиҗәләрне игълан итте. Рәсми саннарга караганда, илдә узган сайлауда катнашу күрсәткече 77,4 проценттан да артып киткән. Бу – рекордлы сан. Чагыштыру өчен: 2018 елда дәүләт башлыгын сайлаганда, ул 67,5 процент тәшкил иткән. Ә иң зур сан 2008 елда теркәлгән булган. Ул вакытта тавыш бирергә 69,8 процент сайлаучы килгән. Белгечләр дә бу саннарга игътибар итәргә чакыра. Сайлауда кемнең җиңәсе алдан ук шик уятмады. Ә менә тавыш бирергә күпме кешенең килгәне үзе үк ил халкының ни дәрәҗәдә берләшкәнен күрсәтә.

Бу урында Президент сайлауның тәүге тапкыр өч көн буе дәвам итүен дә искәртик. Моңарчы мондый хәлнең булганы юк иде әле. Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының беренче проректоры, профессор Игорь Бикеев әйтүенчә, бу – иң беренче чиратта халыкка уңайлы булсын өчен эшләнде. «Шәхси тормышлары, эш вазыйфаларына карап, кайсы вакытның уңайлы булуын сайлаучылар үзләре билгели. Бәлки, кешенең ял көнен гаиләсенә багышлыйсы, сайлау участогы урнашкан торак пункттан читкәрәк китәсе киләдер», – диде ул.

Россия Үзәк сайлау комиссиясеннән алган саннарга караганда, сайлауда үзен үзе тәкъдим иткән гамәлдәге Илбашы Владимир Путин 87,28 процент тавыш җыйган. Икенче урында – КПРФ партиясеннән Николай Харитонов. Аны ил халкының 4,31 проценты хуплаган. «Новые люди» партиясеннән Владислав Даванков өчен кешеләрнең 3,85 проценты тавыш биргән. ЛДПР партиясеннән Леонид Слуцкийны сайлаучылар 3,2 процент тәшкил иткән.

Татарстанның Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматларына караганда, сайлау участокларына килүчеләрнең 88,74 проценты Владимир Путин өчен тавыш биргән. Николай Харитоновны халыкның 4,83 проценты хуплаган. Леонид Слуцкий өчен бирелгән тавышлар – 3,93 процент. Владислав Даванков республикада 1,53 процент тавыш җыйган. Рәсми саннардан күренгәнчә, Татарстанда Президентны сайлауда 2480516 кеше катнашкан. Бу – сайлау хокукына ия булучыларның 84,6 проценты.

Хәер, бездә сайлауга бәйле саннарның зур булачагын алдан ук фаразладылар.

– Татарстанда сайлаучылар бик җаваплы, – диде КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институтының фәнни эшчәнлек буенча директоры урынбасары Мария Ефлова. – Бу – республикада яшәүчеләрнең үзенчәлеге. Шуңа күрә авылларда да, шәһәрләрдә дә сайлауда катнашучылар күрсәткече югары.

Республикада 15–17 мартта сайлау участокларыннан чыгучылар арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре дә шуны күрсәткән.

– Сораштырудан күренгәнчә, Владислав Даванков өчен – халыкның 1,9 проценты, Владимир Путин өчен – 89, Леонид Слуцкий өчен – 4, Николай Харитонов өчен 4,2 проценты тавыш биргән, – дип, сайлау участоклары ябылгач, алдан алган саннар белән уртаклашты Мария Ефлова.

Алай гына да түгел, Татарстанда сайлау чын гаилә бәйрәменә әверелде. «Бөтен гаилә белән – сайлауга» акциясе кысасында өч көн дәвамында берәр автомобиль уйнату бәйгесендә генә дә республикада яшәүче 70 меңнән артык кеше катнашкан. Сайлау участокларындагы бәйрәм рухы Татарстанга килгән чит ил күзәтүчеләрен дә шаккатырган хәтта.

– Сайлау барышында Татарстандагы күп кенә сайлау участокларында булдым. Беләсезме, мондагы бәйрәм мохите гаҗәпләндерде, – диде халыкара эксперт, Испания геосәясәт институты вәкиле, тарихчы Хосе Мануэль Менендес Манхон. – Испаниядә сайлау күбрәк гражданнарның бурычы буларак кабул ителә. Ә монда халык сөенә-сөенә сайлауга бара, гаиләләре, кечкенә балалары белән киләләр, аларның барысының да йөзләрендә – шатлык. Тавыш бирүнең өч көн дәвам итүе дә үзенчәлекле. Бездә сайлау бер генә көн уза. Гомумән, биредә сайлау системасы камил. АКШ белән чагыштырсак, анда сайлау тирәсендә даими рәвештә бәхәс куба. Ә монда барысы да ачыктан-ачык.

Ахыры 2 нче биттә >

Кайда күпме алалар?

Узган елда Татарстан хезмәт хакы күләме буенча төбәкләр арасында 30 нчы урынга чыккан. «РИА Новости» үткәргән тикшеренү нәтиҗәләренә караганда, 2023 елда республикада химия сәнәгатендә иң югары эш хакы (90 мең сум) түләгәннәр. Рейтингта безнең күршеләр – Яһүд автономияле өлкәсе (29 нчы урында, йөк ташучы компания хезмәткәрләренә 90 мең сум түлиләр) һәм Свердловск өлкәсе (31нче урын, IT һәм элемтә өлкәләре вәкилләре 90 мең сум алып эшли).

Мәскәү, гадәттәгечә, исемлектә беренче урында тора (банк хезмәткәрләре иң күп хезмәт хакы ала – 256 мең сум). Сахалин өлкәсе (казылма байлык чыгаручылар – 232 мең сум) – икенче, Ямал-Ненец автономияле округы (нефть һәм газ чыгаручылар – 220 мең сум) өченче урынны алган.

Төбәкләрнең беренче дистәсенә шулай ук Мурманск өлкәсе, Саха (Якутия) Республикасы, Чукотка, Камчатка крае, Ненец автономияле округы, Санкт-Петербург һәм Магадан өлкәсе кергән.

Ә менә Калмыкия (иң югары хезмәт хакы 47 мең тәшкил иткән) исемлектә иң ахыргы урынны алган. Мордовия республикасы, Псков һәм Иваново өлкәләре, Алтай краенда да хәлләр мактанырлык түгел.

Язгы өмет

Ташу көчле булган очракта Татарстанның 220 торак пунктын су басарга мөмкин. Аларда 13636 кеше яши. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган Гадәттән тыш хәлләр комиссиясе утырышында хәбәр иттеләр.

Татарстанның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе белгечләре сүзләренчә, республикада ким дигәндә бер атна уңайлы һава торышы саклаunion. Ягъни көндез җылы, төнлә суык булачак. Мондый шартларда кар катламы тигез эрер дигән өмет тә бар.

Шулай да ташуга алдан әзерлек алып баралар. Татарстанның гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфасын вакытлыча башкаручы Николай Суржко сүзләренчә, моның өчен 988 млн сум акча тотылган.

«38 гидротехник корылманы төзекләндердек. 106 чакрым елга-күлләрне чистарттык. Яр буйларын ныгыттык. 10 мең берәмлектән артык сүүткәргеч торбаларны чистарттык. Ул-бу була калса, 41 мең кешелек 158 вакытлыча яшәү пунктлары бар», – диде ул.

Ярминкәләр башланды

Узган шимбә – 16 мартта республикада язгы ярминкәләр башланды. Фермерлар сәүдәнең беренче көнендә барлыгы 71,1 миллион сумлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, бигрәк тә яшелчәгә, йомырка һәм сөт ризыкларына ихтыяҗ зур.

Ярминкә Казанның 14 мәйданчыгында, шулай ук Чаллы, Түбән Кама һәм Яшел Үзәндә үткәрелгән. Язгы сәүдә башка районнарда да уздырылачак.

Тәгаенләп әйтсәк, фермерлар ярминкәнең беренче көнендә 106,8 тонна яшелчә, шул исәптән 60,2 тонна бәрәңге, 16,5 тонна сөт, 44,1 тонна шикәр комы, 246,1 мең данә йомырка, 87,8 тонна ит (48 тоннасы – сыер ите) саткан.

Язгы ярминкәләр 8 апрельгә кадәр дәвам итәчәк.

Һәр баш исәптә

Татарстанда шәхси хуҗалыкларда терлекләр һәм кош-кортларның барысы да исәп системасына кертелгән. Авыл хуҗалыгы оешмаларына килгәндә, мөгезле эре терлек – 98 процентка, вак терлек – 49, дуңгыз – 72, атлар – 33, кош-корт 88 процентка маркировкаланган.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов әйтүенчә, чирләр таралуны кисәтү, аларның чыганакларын, таралу юлларын ачыклау өчен кирәк бу. Аның сүзләренә караганда, терлекләрне вакытында маркировкаламау административ җаваплылыкка китерергә мөмкин.

Барлык мәгълүматлар терлекләрне исәпкә алу һәм теркәү буенча илкүләм системага кертелә. Ветеринария буенча үткәрелгән бөтен чаралар шушы федераль системада саклаunion.

Хәзерге вакытта ветеринария белгечләре урыннарда авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре һәм халык өчен консультацияләр үткәрә. Терлекләрне маркировкалау мәсьәләсе буенча 8(843) 221-77-41 телефоны аша мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Ифтар – 2024

Бер табында

Өч тонна ит, бер тонна дөге, тоннадан артык кипкән җиләк-җимеш, ике тонна яшелчә һәм ике мең литр су... XI Республикакүләм ифтарга табын әзерләү өчен әнә шулкадәр азык-төлек тотылачак. Быел ул 29 март көнне узачак.

dumrt.ru

Илебездәге иң зур авыз ачу мәҗлесләренең берсе саналган әлеге чара быелдан яңа дәрәҗәгә чыга. Республикакүләм ифтар хәзер «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме канаты астында үткәреләчәк.

Татарстан Диния нәзарәтенең аппарат җитәкчесе Ирек Арсланов сүзләренә караганда, чарага күпсанлы дәрәҗәле чит ил кунаклары чакырулы. Аерым алганда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Кувейт, Бахрейн, Согуд Гарәбстаны, Катар белән Төркиядән вәкилләр киләчәк. Быел Республикакүләм ифтарда дөньякүләм танылган Коръән укучылар һәм нәшид башкаручылар да катнашыр дип көтелә.

– Республикакүләм ифтар, елдагыча, «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданчыгында булачак. Уникенче тапкыр узачак чарада 12 мең кеше катнашыр дип көтелә. Шуларның 5,5 меңе – ир-атлар, калганы – хатын-кызлар. Билетлар элеккеге тәртиптә, иң беренче чиратта, мәчетләр аша таратыла башлаячак, – дип ачыклык кертте Ирек Арсланов журналистлар белән очрашуда.

Гадәттәгечә, авыз ачу вакыты җиткәнче Республикакүләм ифтар катнашучыларын бай мәдәни программа көтә. Бу юлы ул Россиядә Гаилә елына һәм Татарстан Диния нәзарәте игълан иткән гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше темасына багышланачак.

18 сәгать 17 минутта, кояш баю белән, Республикакүләм ифтарда катнашучылар, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга ияреп, җәмәгать белән ахшам намазын укыячак һәм ифтар кылу залына узачак. «Туган авылым» милли-туристик комплексы җитәкчесе Радик Габдрахманов сүзләренә караганда, менюга пылау, кипкән җимешләр, камыр ризыклары, тәм-томнар, су, төрле җиләк-җимеш кертелгән.

– Аларны әзерләү өчен өч тонна ит, бер тонна дөге, тоннадан артык кипкән җиләк-җимеш, ике тонна яшелчә һәм ике мең литр су тотылачак. Ифтар ризыклары уңайлы контейнерларга салыначак. Авыз ачу тәмамлангач, кешеләр аларга гаиләләренә күчтәнәчләр салып алып китә алачак, – дип сөйләде Радик Габдрахманов.

Быелгы ифтарны оештыруда 16 яше тулган һәм аннан өлкәнрәк 700 волонтер ярдәм итәчәк. Әлеге изге эштә катнашу өчен (843) 237-86-18 телефон номерына шалтыратырга кирәк.

Сүзгә-сүз

2024 гаилә елы

Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ, Татарстанның баш казые:

– Адәм баласына гаиләле булып яшәргә кирәк. Гаилә дигән дәүләттә дин тотарга, татарча сөйләшергә беркем дә тыймый. Гаилә дәүләтенең президенты – үзебез бит. Оныклар белән русча сөйләшәбез дә аннары хөкүмәтне сүгәбез. Бүген булган мөмкинлекләрдән чыгып эш итәргә кирәк.

ТАТАРСТАНДА – СӨТ ҖИТЕШТЕРҮ

Татарстанда соңгы ике айда 283 мең тонна сөт җитештерелгән, бу узган ел белән чагыштырганда 23 мең тоннага, ягъни 9 процентка күбрәк. Бу хакта республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итә.

ИҢ КҮП СӨТ

Минзәлә	Бөгелмә
Әлки	Саба
Кукмара	Азнакай
Балтач	Актаныш
Алабуга	Арча

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ: ПРОВИНЦИЯЛӘР БӨЛӘ

Бөек кризисның дәһшәтле хәбәрләре планетаның бар почмакларыннан да яңгыр булып ява. Кечкенә генә Эстониядә сәнәгать, төзелеш, IT тармакларында барлык күрсәткечләр җимерелә. Зур банкның төзелеш бүлеге җитәкчесе: «Германия күчемсез милек тармагындагы дүрт еллык кризисның уртасында тора», – дип белдерде. Кризис кирәге беткән объектларның күпләп сатылуына һәм зур югалтуларга китерә. Европа Үзәк банкы моның ставкаларны күтәрү нәтиҗәсе икәнен яшерми. Җимерелү сәнәгать тармакларында гына түгел, дәүләт финанслары өлкәсендә дә ачык күренә. Германиянең финанс министры Линдер, хөкүмәт курсны үзгәртмәсә, дәүләт финансларының контрольдән чыгарга ихтимал икәнлеген әйтте. Популяр интернет эшмәкәре Ким Дотком Америка финансларының җимерелү алдында булуын хәбәр итә. «АКШ хөкүмәте – бөлгенлектә һәм чыгу юлы юк, – ди ул. – Кем Президент булу бернинди әһәмияткә ия түгел. Понци схемасы ахырына якынлашып килә». Укучыларга искәртәбез: Понци схемасы дип, яңа катнашучыларның акчасын алдагы инвесторларга табыш итеп түләү хисабына яши торган финанс пирамидасын әйтәләр. Россиядә андый пирамиданы Мавроди төзеп карады. Яңа ачык авызлар килү тукталуга, пирамида җимерелә.

Кытайда мондый схема үзенең түнтәрелү этабына керде. Илдә икътисадый үсеш бик сүлпән. Чин портларында сатылмаган металл запаслары өелә. Тимер рудасына бәя тоннага 142 доллардан 107 долларга кадәр төште. Фаразлар бәянең 100 долларга кадәр төшәчәген вәгъдә итә.

Үткән атнада Country Garden – иң эре кытай төзелеш компанияләренең берсе үзенең юань облигацияләре буенча купоннарны түләмәде. Үткән елның октябрендә инде ул доллар әҗәтләрен түләми кичектереп торган иде. Утыз көн эчендә бурычын түли алмаса, компания рәсми рәвештә банкрот булып саналачак.

Чин провинцияләре банкротлык сызыгына килеп терәлде. Сигез провинциянең бурычларының процентын түләү өчен генә дә керемнәренә караганда зуррак сумма таләп ителә. Кеше яшәми торган йортлар, буш торучы аэропротлар төзү сәясәте, чынбарлыкка бәрелеп, чәлпәрәмә килеп ята. Февраль аенда илдә кредитлар бирү темплары тарихта күрелмәгәнчә түбән.

Җитмәсә, Америкадан Трамп, Президент була калса, Кытай автомобильләренә – 50 процентлы, башка товарларга 60 процентлы пошлина кертәчәген әйтеп нәгърә ора. Хәер, ул бер кытайларга гына түгел, американнарга да яный. Бер-ике көн элек кенә ул: «Әгәр мине сайламасалар, канлы мунча башланачак, бөтен ил өчен – канлы мунча», – дип игълан итте.

Россиядә

БЕЗДӘ ДӘ РЕЦЕССИЯМЕ?

Глобаль икътисадның мәтәлчеге Россиягә дә авырлыклар белән яный. Илнең төп доноры булган Кытай элеккечә ярдәм итә алмый, чөнки үз хәле хәл булганлыктан, безнең чималны күпләп алудан туктарга җыена. Җитмәсә, Көнбатыш Мәскәү белән хезмәттәшлек иткән илләргә икенчел санкцияләр белән янавын көчәйтә һәм ул янау нәтиҗә бирә. Россия бизнесы Кытай банкларына күчерелгән акчаның барып җитмәвеннән зарлана. Акча я эленеп кала һәм кире кайта, я бөтенләй югала. Барып җиткәне дә юлда бик озак йөри. Нәтиҗәдә экспорт та, импорт та зыян күрә. Үзәк банк гыйнварда экспортның 14,1 процентка кимүен хәбәр итә. Импорт 12,6 процентка кимегән. Үзәк банк экспорт кеременең якынча ике айга соңга калып килеп җитүен әйтә. Дөрес, безнең чиновниклар сер бирми: моннан соң ил икътисады экспортка түгел, эчке ихтыяҗны канәгатьләндерүгә йөз тотачак, диләр. Ягъни үз җитештергәнебез үзебезгә дә җитеп бетми әле. Моның белән килешмичә дә булмый, чөнки күреп торабыз бит: дроннар һөҗүме нәтиҗәсендә көн саен диярлек бер я ике нефть эшкәртү заводы сафтан чыга. Иң күп нефть продуктлары экспортлаучы илдән бензин кытлыгы кичерүчегә әйләнүебез ихтимал.

Үзәк банк бер нәрсә белән сөендерә сөендерүен. Бәяләр үсеше, үзенең югары ноктасыннан узып, темпны киметә, ди. Дөрес, әлегә инфляция 4 процентан зуррак, әмма инде 7–8 процент ук түгел. Көенечле сөенеч бу ләкин. Ихтыяҗның кимүен аңлата. Бездә барысы да ал да гөл дип музыка уйнатсак та, инде үткән ел ук дәүләт компанияләренең эше уңышлы бармаган. Бюджетка 2023 елда түләгән дивидендлар 2022 елгыдан ике тапкыр кимрәк һәм 339 миллиард сум гына тәшкил иткән.

Тагын бер кыек күрсәткеч тауга менеп барудан туктавыбызны искәртә. Россиядә эшче кулларга ихтыяҗ кимегән. Белгечләр моның берничә сәбәбен әйтә. Вакытлыча гына булырга мөмкин дигән фикер дә бар. Әмма, гомумән алганда, кадрларның кирәге бетү – рецессия билгесе ул. Хөкүмәт акчаны каян алыр, дип бик борчылырга кирәкми. Әле Милли муллык фонды бар. Сумның девальвациясе дә булыша ала. Сайлауның беренче көнендә доллар белән евро янә югары күтәрелергә азапланды. Сайлау үткәч, аларга ихтыяр бирелер дип уйлыйк. Девальвация үзе генә дә бюджетка бик күп акчаны безнең кесәдән алып бирәчәк. Муллык фондын да үстерәчәк.

САЙЛАУ-2024

ВЛАДИМИР ПУТИН: «КӨЧЛЕ, БӘЙСЕЗ ҺӘМ ИРЕКЛЕ РОССИЯ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАМ!»

Ватанпәрвәрлек, ышаныч һәм теләктәшлек күрсәткәнегез өчен рәхмәт! Гамәлдәге Россия Президенты Владимир Путин якшәмбе кичендә ил халкына шулай дип мөрәҗәгать итте.

Сайлау һәм киләчәккә максатлар

Минем сайлау участокларына килгән һәм тавыш биргән барлык кешеләргә рәхмәт белдерәсем килә. Илдә хакимият чыганагы булып Россия халкы тора.

Безнең алдыбызда бурычлар бик күп. Безне куркытырга һәм басарга тырышсалар да, без бердәм булганда, моны берәү дә эшли алмаячак. Элек тә мөмкин түгел иде һәм киләчәктә дә мөмкин булмас.

Күпмилләтле дәүләт буларак, бездәге нәтиҗәләр уникаль. Бу – алга баруыбызның төп шарты да. Алда бик күп бурычлар тора. Сайлау нәтиҗәләре – шушы бурычларны хәл итү, куелган максатларга ирешү гарантиясе ул. Теләктәшлек белдерүегез һәм ышанычыгыз өчен рәхмәт!

Көнбатыш турында

Көнбатышның бездәге сайлауга карата нинди фикердә булачагын алдан ук чамаларга мөмкин иде. Алар бит безгә каршы кораллы юл белән көрәшә. Алар бит үз алдына Россиянең мөстәкыйльлегенә һәм икътисадый үсешенә каршы тору максатын куя.

Яңа хөкүмәт турында

Гомумән алганда, администрациядәге команда нәтиҗәле эшләде. Хөкүмәтнең дә, Үзәк банкның да, Президент администрациясенең дә эше канәгатьләндерерлек. Хәзер сорау шундый: гомуми нәтиҗә тагын да яхшырак булсын өчен, кемнең нинди урында булуы дөресрәк? Борчылырга кирәк түгел: закон буенча, бу сорауларны хәл итү өчен 2,5 ай вакыт бирелә.

Идарәчеләр корпусы турында

«Геройлар заманы» проекты турында әйткән идем инде. Махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашу вакытында башыма килгән фикер бу. Үз-үзләрен аямыйча, Ватан өчен көрәшкән кешеләрдән киләчәктә илнең идарәчеләр корпусын туплап булыр иде, дигән фикергә килдем. Әмма аларны әзерләргә кирәк. Барысының да югары белеме юк. Медицина, бизнес, оборона, дәүләт идарәсе, башка тармаклар – алар кайда телиләр, шунда эшләрләр.

Хыял турында

Мин көчле, бәйсез һәм ирекле Россия турында хыялландым. Бу хыяллар тормышка ашар дип ышанам!

Владимир Путинны чираттагы җиңүе белән чит ил лидерлары да котлады. Аңа дөньяның төрле илләреннән котлаулар килә.

Владимир Путин Азәрбайҗан, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм Үзбәкстан Президентлары белән шәхсән телефон аша сөйләшкән. Бу ил җитәкчеләре Путинны бу сайлауда җиңүе белән котлады, эчке һәм тышкы сәясәттә алып барылган юнәлешен хуплауларын һәм тавыш бирү барышында сайлаучыларның активлыгын билгеләп үттеләр.

Россия Президентын тәбрикләүчеләр арасында Боливия Президенты Луис Арсе, Никарагуа Президенты Даниэль Ортега, Гондурас Президенты Сиомара Кастро, Куба Президенты Мигель Диас-Канель, Гагауз автономиясе (Молдавия) лидеры Евгений Гуцул, Мьянма премьер-министры Мин Аун Хлайн бар иде. Моңа өстәп, Владимир Путин Рим папасы, Кытай Халык Республикасы, Иран, Корея, Сербия Республикасы лидерларыннан да тәбрикләүләр кабул итте.

Илнең терәге

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов 17 март кичендә «Ак барс Арена» стадионында Россия Президентын сайлау хөрмәтенә оештырылган бәйрәм концертында булды.
– Бу изге эштә катнашкан өчен сезгә ихлас рәхмәтемне җиткерәм, – дип мөрәҗәгать итте ул. – Җиңел заманнар түгел, шулай да без дошманнарыбызны җиңәчәкбез, барлык авырлыкларны узачакбыз. Моңа бернинди шик юк. Безнең республика – Россиянең терәк субъекты. Ә безнең башкалабыз Казан – иң яхшы шәһәр! Ни өчен иң яхшысы? Чөнки биредә сезнең кебек искиткеч кешеләр яши. Безнең республикабыз, безнең башкалабыз федераль үзәк һәм шәхсән Владимир Путинның ярдәме бәрабәренә алга таба да чәчәк атачак. Без шәһәребезне дөньядагы иң яхшы шәһәр итәчәкбез!

БЕРГӘ БАРАБЫЗ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Танзаниядән килгән халыкара күзәтүче Фрэнсис Альфред Мвакабумбе да республикада сайлауны оештыруны югары бәяләде.

– Өч көн дәвамында Татарстанда унбишләп сайлау участогында булдым. Иң элек шуны искәртеп үтәсем килә: сайлау эше югары дәрәҗәдә һәм ачыктан-ачык оештырылган. Аерым алганда, күзәтү камералары көн дәвамында эшләп тора. Бюллетеньнәрне үтә күренмәле урналарга салалар. Биредә бернинди кимчелек тә күрмәдем. Россия Президентын сайлау – иң демократияле сайлау. Башка илләргә биредәге тәҗрибәне өйрәнергә киңәш итәр идем, – диде ул.

Фикер

Сайлау нәтиҗәләрен ничек бәялисез?

Андрей БОЛЬШАКОВ, КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр, дөнья сәясәте һәм дипломатия кафедрасы җитәкчесе, сәяси фәннәр докторы:

– Россия Президентын сайлау нәтиҗәләре дөнья күләмендә әһәмияткә ия. Ул, һичшиксез, дөнья сәясәтенә дә, халыкара мөнәсәбәтләр үсешенә дә тәэсир итәчәк. Сайлау барышында Россиягә чит илләр тарафыннан мәгълүмати куркынычсызлыкка янаудан алып, Украина территориясеннән хәрби террорчылык һөҗүменә кадәр басым ясалды. Әмма Көнбатыш илләре башлаган гибрид сугышы капма-каршы нәтиҗә бирде. Россия халкы берләште. Гамәлдәге Илбашының Президентны сайлауда 87 процент тавыш җыюы, сайлауда катнашучыларның 74 процентан да артып китүе әнә шуның белән аңлатыла. Гомумән алганда, сайлаулар зур хокук бозуларсыз узды. Алай да, ил күләмендә бюллетеньнәрне бозу, сайлау участокларында янгын чыгарырга маташу кебек очракларга бәйле 60тан артык җинаять эше кузгатылды. Әмма болар сайлау эше барышына комачау итмәде. Тавыш бирү гадел, чиста һәм ирекле узды. Сайлауда ышанычлы җиңү Россиягә махсус хәрби операциядә дә өстен чыгарга, дөнья күләмендә тынычлыкның яңа тәртибен урнаштырырга, илне Россия Президентының Федераль Җыенга Юлламасындагы юнәлеш буенча алып барырга мөмкинлек бирер дип саныйм. Татарстан сайлау кампаниясе барышында һәр яктан да үрнәк күрсәтте. Республикада сайлауда катнашучылар һәм Владимир Путин өчен тавыш бирүчеләр саны ил күләмендәге уртача күрсәткечләрдән дә зуррак. Федераль хакимият Татарстанны инновацияләр һәм үсеш мәйданы итеп күрсәтә. Сайлау барышында без моны дәлилләдек.

Ринат ФАЗЫЛОВ, Владимир Путинның ышанычлысы, Халык фронтының Татарстандагы төбәк башкарма комитеты җитәкчесе, «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте координаторы:

– Бу гадел һәм ачыктан-ачык сайлау иде. Үземнән өстәп, шуны әйтәсем килә: минем карашка, дөреслек һәм гаделлек күзлегеннән бюллетеньдә дәүләтебез башлыгы, аннан бигрәк башкомандующий булырга лаеклы һәм тиешле бер генә фамилия бар иде. Ул да булса – Владимир Путин. Гамәлдәге Президент халык мәнфәгатьләрен аңлап эш итә, илдә яшәүчеләргә кагылышлы социаль сәясәт алып бара. Владимир Путин тырышлыгы белән дөнья мәйданында илебезнең абруе үсә. Россиядә яшәүчеләр соңгы дистә елларда тәүге тапкыр үзен бай тарихы, мәдәнияте, традицияләре, фәне булган бөек дәүләт халкы итеп хис итә башлады. Сайлау нәтиҗәләре әнә шул хакта сөйли.

ФАЙДАЛЫ ТАВЫШ

САЙЛАУДА КАТНАШКАН ӨЧ ГАИЛӘ МАШИНАЛЫ БУЛДЫ

Сайлау көннәрендә Татарстанда өч машина уйнаттылар. Бәйгедә катнашу өчен тавыш биргәннән соң, гаилә белән фотога төшеп, аны социаль челтәрләргә урнаштырырга кирәк иде. «Бөтен гаилә белән сайлауга» фотобәйгесендә барлыгы 72 меңләп кеше бәхетен сынап карады. Lada Vesta откан гаиләләрнең сөенечен «ВТ» хәбәрчесе дә уртаклашты.

«Хатынныкы яңа әле»

Беренче машинаны Актаныш районыннан Флүдә һәм Алмаз Гардисламовлар гаиләсе отты. Алар Яңа Кормаш авылында яши. Флүдә ханым – математика укытучысы, Алмаз әфәнде янгын сүндерү машинасын йөртә. Ике бала үстергәннәр. Хәзер инде аларның үз тормышы. Гардисламовлар дүрт онык сөяләр. «Машина уйнатканны телефоннан карадык. Үз фотобызны күргәч, шаккаттык. Төн буе йоклап булмады. Әллә кемнәр котлый. Туганнар шалтырата, авылдашлар. Бөтен район белән, Татарстан белән тәбрикләделәр. Моңа кадәр бернинди бәйгедә катнашканыбыз юк иде. Беренче тапкыр оттык. 1 февральдә Флүдәгә 55 яшь тулды. Бу машинаны юбилей бүләге итеп кабул иттек. Әмма машина миңа була. Чөнки машинам искергән иде инде. Флүдәнең үз машинасы яңа әле», – диде гаилә башлыгы.

«Искегә дә риза идем»

16 мартта бәхет Лаеш районының Усад бистәсендә яшәүче Хөснетдиновларга елмайды. Гаилә башлыгы Ленар тумышы белән Чүпрәледән, Алинә – Буа кызы. Бер кыз үстерәләр. «Мин әлегә өйдә генә, ирем – үзмәшгуль. Сайлауга барып, фотоны куйганда, өч машинаның берсе миңа була, дип шаярткан идем. «Амин» дигән вакытка туры килгән. Бәхет дими, ни дисең?! Иремне машина сорап аптырата идем. Һич югы искене булса да алып бир, дидем. Менә бит яңасы эләкте, – дип сөенече белән уртаклашты Алинә. – Бик тә машина аласым килде. Бөтен эш Казанда бит. Шәһәргә йөрергә хыялландым. Әле мин машина отканыбызга ышанмадым да. 28 мең кеше арасыннан безгә чыгар дип кем уйлаган? Оештыручылар шалтыраткач кына, чын икән, дидем. Башкаларга да көтмәгән җирдән сөенеч килсен».

«Әлегә трамвайда йөрим»

17 март кичендә машина откан Митрофановларны без «Ак барс Арена»да эзләп таптык. 36 яшьлек Эльвина сайлау концерты карарга килгән. «Салават «Мин яратам сине, Татарстан»ны җырлаганда, туганым шалтыратып, безнең машина отканны әйтте. Шаяру дип уйладым. Әмма башкалар да котлый башлагач, ышандым, – диде ул. – Ирем Андрей да, мин дә тумышыбыз белән Кайбычтан. Казанда яшибез. Фотога төшеп куйгач та, күңелдә машина отасы килү теләге булды инде ул. Ә менә безгә булыр дип уйламадым да. Бер дә ышанмадым. Әлегә машинаны нишләтәсебез билгеле түгел. Өйгә кайткач, хәл итәрбез инде. Бүген трамвайга утырып кайтып торам».

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МАТУР КИЛӘЧӘК ӨМЕТ ИТӘБЕЗ

Үзем күрдем

Биектау районының Олы Битаман авыл җирлегендә Россия Президентын сайлау иртәнге сәгать 8дә башланды. Без килеп җиткәндә, яше-карты, апалар һәм абыйлар сайлауга ашыга иде. Шунысы күзгә ташланды: сайлауга гаиләләре белән бергәләп килүчеләр шактый күп булды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гариповлар гаиләсе сайлауга өч буын бергә килгән.

Дүрт авылны (Олы Битаман, Кече Битаман, Ювас һәм Бикнарат) берләштерүче җирлектә 882 кеше яши, аларның 757се – тавыш бирү яшендә.

– Безнең җирлектә халык актив. Бигрәк тә шимбә, якшәмбе көннәрендә кеше күп килә. Казаннан да яшьләр кайта. Без ишекләрне ачуга, чиратта 15 кеше җыелган иде инде, – диде 1297 нче сайлау участогы комиссиясе рәисе Гөлнара Камалиева. – Без беренче булып сайлаган кешегә сайлау логотибы сурәтләнгән кружка әзерләгән идек. Әлеге бүләк Наил Дәминовка эләкте. Ул мәктәп балаларын автобуста йөртә. Эшен тәмамлауга ук Россия Президентын сайларга килгән. Моннан тыш, беренче тапкыр сайлауга килүче яшьләребезгә дә бүләкләр әзерләдек. Ә җирлектә андыйлар 13 кеше икән.

Гөлнара Камалиева әйтүенчә, күрше авылларда яшәүче өлкән яшьтәге кешеләрне өйгә барып сайлаталар. Әйтик, Ювас авылында сайлау яшендәге 82 кеше булса, шуның 20се өйдә сайлый.

– Комиссия өчен өч көн сайлау мөмкинлеге булу күпкә уңайлы. Бер көн булганда, зур чиратлар хасил була иде. Болай эшләгәндә аз-азлап киләләр, тәртип белән генә керәләр, – диде ул.

«Балалар бәхете өчен сайлыйм»

85 яшьлек Дания Билалова да сайлауда бик теләп катнаша. Гомер буе балалар укыткан хөрмәтле укытучы хәзер дә тормышта бик актив. Авыл җирлегенең ветераннар советын җитәкли.

– Үз гомеремдә бик күп сайлауда катнашканым булды. Заманында үзем дә сайлау комиссиясе рәисе булып эшләдем. Сайлауның ил өчен мөһимлеген бик яхшы аңлыйм. Менә бүген дә бик теләп килдем. Комиссиядә эшләүче кызлар сайлар өчен өйгә генә килергә тәкъдим иткәннәр иде дә, үзебезгә тиешле кешене участокка үз аякларымда барып сайлап кайтачакмын, дидем, – ди Дания апа.

Өлкәннәр генә түгел, сайлауда яшьләр дә, урта буын да бик актив. Мәдәният йортының ишекләре ябылып тормады. Авыл зур булгач, кешеләр акрын гына килеп, сайлап китә тордылар.

Әнә Биектауда яшәүче Айсылу һәм Инсаф Гариповлар, Россия Президентын сайлар өчен, җомга көнне авылга махсус кайтканнар. Сайлау участогына алар әти-әниләре белән бергәләп килгән. Яшь гаилә үзләре белән ике улын да алган.

– Сайлау хокукы бирелгәннән башлап, бер генә вакыйганы да калдырганыбыз юк, чөнки бу – безнең гражданлык бурычыбыз. Балаларыбыз да шуны күреп, белеп үссеннәр өчен, аларны да үзебез белән алып килдек, – диде Айсылу.

Инсафның әти-әнисе Лара ханым белән Илгиз Гариповлар авылда яши.

– Без менә шулай бер гаилә булып, матур итеп сайлауга килдек, чөнки ул – безнең бурычыбыз. Фотобәйгедә катнашып, машина оту турында да хыялланабыз. Анда да үзебезнең бәхетне сынап карамакчы булабыз, – диде Лара ханым.

Гаиләле сайлау

Гомумән, бу көнне сайлауга гаиләләре белән бергәләп килүчеләр күп иде. Әниле-уллы Ләйсән һәм Айнур Идрисовлар – әнә шундыйлардан.

– Бу вакыйга илебез өчен бик мөһим, шуңа күрә беребезнең дә читтә каласыбыз килми. Улым белән бүген килдек, кызым белән киявем, тагын бер улым иртәгә сайлаячаклар. Алар бүген эштә, – диде Ләйсән.

Фотобәйгедә катнашып, машина оту мөмкинлеге турында гына ишеткәннәре булмаган икән. Бу хакта белгәч, һичшиксез катнашып, бәхетләрен сынап карарга булдылар.

Сайлауга килгән тагын бер матур, тулы гаилә Сабирҗановлар иде. Әниләре Рәдисә апа, улы Рамил белән килене Гөлчәчәк янәшәсендә өч балалары да атлый иде. Балалар зурларны игътибар белән күзәтеп, артларыннан бер адым да калмады.

– Без балаларга да үзебездән үрнәк күрсәтергә тиешбез, шуңа күрә бу юлы аларны да калдырмаска булдык. Бер генә тапкыр да сайлауда катнашмый калганыбыз юк, – диде Гөлчәчәк.

– Ил язмышы өчен бер генә кеше дә битараф түгелдер, дип уйлыйм. Һәркем үзеннән өлеш кертеп калырга тырыша, – дип, хатынының сүзләрен җөпләде Рамил Сабирҗанов та.

Матур, төзек йортларда яшәүче тырыш, һөнәрле һәм ачык йөзле Олы Битаман авылы халкы сайлауда да менә шулай бердәмлек күрсәтә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Иннополиста бар да кәттә

«Татар-информ»

Иң яшь сайлаучылар – Иннополиста. Аларның уртача яше – 31. Бу хакта Россиянең иң яшь шәһәрендәге участокта тавыш бирү вакытында Татарстан вице-премьеры Роман Шәйхетдинов хәбәр итте.

Сайлауга килүчеләрне ишек төбендә үк робот эт каршы алды. Кемдер аңа: «Бир бишне», – дисә, кемдер башыннан сыйпады. Теләгәннәр нейрочелтәр ярдәмендә картина да ясап карады. Син ясаган гади рәсемне ул матур бер картинага әйләндерә. Нейрорәссам янында бөтерелүчеләр дә шактый иде. «Киләчәк уеннары» геройлары белән фотога да төштеләр.

– «Иннополис» сайлау участогында Президент сайлауда 1500дән артык кеше катнашты. Сайлау барышын чит илләрдән килгән күзәтүчеләр күзәтте. Алар – Испания, Бразилия һәм башка чит ил вәкилләре. Күзәтүчеләр, сайлау системасы белән танышып, кызыксындырган сорауларын бирде, – диде Роман Шәйхетдинов. – Бу – безнең гражданлык бурычыбыз, илнең киләчәген сайлау хокукы. Тагын бер кат илнең образын формалаштыруда катнашу мөмкинлеге. Илебезнең ирешкән күрсәткечләрен тану һәм халыкара аренада таныту да.

Иннополис мэры Руслан Шагалиев сайлауга гаиләсе белән килде. Хатыны белән бергә тутырган бюллетеньнәрне кечкенә кызлары тартмага салырга булышты. Кызчык та шулай үз өлешен кертте. Руслан Шагалиев Президент өчен тавыш бирү үзенең бурычы икәнлеген әйтте.

Иннополис мәктәбенең математика укытучысы, «Ел укытучысы» республика бәйгесе җиңүчесе Арман Костанян да хатыны Айсылу белән килде. Алар икесе дә шушы шәһәрчектә яши. Хатыны – менеджер. Шәһәр күләмендә төрле концертлар оештыра. Яшь йөрәкләр бер-берсен «Сәләт» лагеренда эзләп тапкан.

– Бу – бик җаваплы көн. Һәр кеше үзенең гражданлык позициясен белдерергә һәм бурычын үтәргә тиеш. Мин укучыларыма да: «18 яше тулган һәркайсыгыз сайлауларда үз тавышыгызны бирегез», – дип әйтәм. Бу безнең илнең, төбәкнең киләчәге өчен мөһим, – диде Арман Костанян.

Айсылу белән кавышуларына – 3 ел. Быел Костаняннарның сайлауга гаилә буларак беренче тапкыр килүе. «Икәүләшеп бару бөтенләй башкача икән», – ди яшь гаилә.

Заманча шәһәрдә сайлау мөмкинлеге турында да кызыксындык. «Россиянең югары технологияләр иң алга киткән заманча шәһәрендә тавыш бирү бик кәттә», – ди Арман.

dumrt.ru

vk.com/mamadysh

ТАУЛЫ, ТУЙЛЫ, ТОЙГЫЛЫ...

Сайлау кәефе

Елның төп сәяси вакыйгаларыннан саналган Россия Президентын сайлау көннәрен Татарстан халкы күңелле уздырды. Районнарда да, башкалада да бу сәяси вакыйганы мөмкин кадәр истәлекле итәргә тырыштылар. Без исә 15–17 мартта булган кызыклы һәм үзенчәлекле хәлләрне барладык.

Туй күлмәге кигән кыздан...

Татарстандагы сайлау участокларына туй күлмәге кигән кызлар, яшь кияүләр дә килде. Сайлау көннәрендә өйләнешеп, ЗАГСтан туры тавыш бирү участогына барган парлар шактый булды. Казан, Әлмәт, Саба, Чистай, Аксубай – кыскасы, республиканың төрле почмакларында гомер кичерүче яшь парлар 15, 16, 17 март көннәрен үзләре өчен икеләтә истәлекле итте. «Бу – уйлап кабул ителгән карар. Һәркем киләчәген үзе сайлый, шуңа күрә без Президент сайлавына баруны кирәк дип таптык», – дип сөйләделәр «Татар-информ» хәбәрчесенә Казанда яшәүче Гөлфия һәм Илмир Идрисовлар.

Кемдер бу көннәрдә «кызыл» туйларын бәйрәм итсә, Арча районының Ташкичү авылында гомер кичерүче Рауза һәм Габделбәр Абдуллиннар 15 мартта «алтын» туйларын каршылаган. 1974 елдан бирле иңне иңгә куеп яшәүче гаилә авылдагы сайлау участогына да бергә килгән. Шунда ук котлаулар да кабул иткән.

Бер егет исә бөтенләй шаккатырды: Казандагы сайлау участокларының берсендә сөйгәненә өйләнешергә тәкъдим ясады. Кызның җавабын чамалыйсыздыр инде?

Башта сайлауга, аннан... тау шуарга

Мамадыш халкы өчен сайлау көннәре икеләтә истәлекле булды. 16 мартта шәһәрдә экстремаль һәм кышкы спорт төрләре комплексы ачылды. Шуңа да бу көнне Мамадыштагы сайлау участокларына махсус киемнәрдән, чаңгы яки сноуборд күтәреп килүчеләр дә булды. Шундыйларның берсе – Захаровлар гаиләсе. Сайлау участогына килгәч: «Тавыш бирәбез дә туры тау шуарга барабыз. Бүген бездә икеләтә бәйрәм! Көнне сәгатьләп планлаштырдык. Тау шуып кайтканнан соң, балалар белән кайнар чәй эчеп җылыначакбыз», – дип уртаклашты Захаровлар.

Сүз уңаеннан, яңа комплекста өч төрле трасса бар. Иң озыны – 650 метрлы. Балалар һәм тюбингларда шуарга теләүчеләр өчен аерым урыннар каралган.

Кайда да була

Татарстаннан барлыгы 100дән артык хаҗи Россия Президентын сайлауда катнашкан. Рамазан ае көннәрендә Мәккәдә кече хаҗ – гомрә кылучылар Россиянең Җиддәдә урнашкан генераль консуллыгына барып тавыш биргән. Бу турыда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте үзенең «Телеграм»дагы каналында хәбәр итте.

Сайлау Татарстандагы тикшерү изоляторларында да узды. Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе хәбәр итүенчә, республикадагы 5 СИЗОда тотылучы 1800 кешенең тавыш бирү хокукы бар. Идарә хәбәр итүенчә, сайлау барышында аларда тәртип һәм хокук бозу очраклары теркәлмәгән. Моннан тыш, төзәтү эшләренә хөкем ителгән 742 кеше дә Конституциядә язылган хокукыннан файдалана алган.

Гаилә бәйрәме

Татарстанда Президент сайлавы Гаилә елы рухында узды. Тавыш бирергә бала-чагасы, әби-бабасы белән килгән гаиләләр хәйран иде. Әйтик, Түбән Кама районының Сухрау авылында яшәүче Фроловлар гаиләсе сайлауга биш буын – 17 кеше бергә килгән. Иң өлкән тавыш бирүче Нина ханымга 88 яшь булса, иң яшь гаилә әгъзасы Ваняга нибары яшь ярым гына. «Сайлауга бик рәхәтләнеп килдек. Без бит илебезнең, балаларыбыз һәм оныкларыбызның киләчәге өчен тавыш бирәбез!» – диде Валентина Фролова.

Фроловлар тату гаилә булуларын махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм әзерләп дә күрсәтә. Алар барысы бергә маскировка челтәрләре үрә, хәрбиләр өчен кирәк-ярак сатып ала. Зур гаиләнең бер әгъзасы – Егор да хәзерге вакытта хәрби операция зонасында.

Коймаклы һәм Салаватлы

Сайлауның соңгы көнен башкала халкы аеруча көтеп алгандыр. Беренчедән, 17 мартта Казанның «Ак барс Арена» мәйданында «Широкая Масленица-2024» республика бәйрәме узды. Аның кысасында Гаилә фестивале үткәрелде. Олысы, кечесе – һәркемнең күңеленә хуш килә торган бәйрәм узды монда. Фестивальгә хатыны Луиза ханым белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да килде. Килгән кунакларны Май чабу бәйрәме белән котлап кына калмады ул, халык белән аралашты, сый-нигъмәтләрдән авыз итте, агач та кисеп күрсәтте. «Безнең дуслык шушындый бәйрәмнәрдә ныгый. Быелгы Май чабуның сайлау көннәренә туры килүе аеруча әһәмиятле. Мондый дуслык ниятләрне тормышка ашырырга ышаныч тудыра», – диде Парламент башлыгы.

Көндез коймак ашап сыйланган халык кичен шушы ук мәйданда зур бәйрәм концертында күңел ачты. Язгы салкынча кичтә башкала халкын һәм кунакларның күңелен Гүзәл Уразова, Фирдүс Тямаев, Салават Фәтхетдинов, чакырылган кунаклардан Хабиб, Ваня Дмитриенко, «Иванушки» төркеме һәм башкалар җылытырга тырышты.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың төзелеш тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Фортэкс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «Монтажспецстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галләмов** Рәүф Әлмөхәммәт улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы **Вәлиәхмәтов** Әхтәм Нурвахит улы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Дельфин» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Җамалиев** Рәсим Бәдретдин улы, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең контроль-профилактика бүлеге башлыгы **Харитонов** Валерий Николаевич; дәүләт статистикасы системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе **Гатауллина** Наталья Вячеславовна; җирле үзидарә органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге башлыгы **Корбанов** Илгизәр Халит улы; республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Камэнергостройпром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары (үсеш буенча) **Якупов** Мәүлет Гәрәй улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте пресс-рам заводы эретеп ябыштыру технологик бүлегенең эретеп ябыштыру буенча баш белгече **Лошков** Александр Петровичка, «Казанның «Союз» тәҗрибә конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте 21 цехы токаре **Молев** Владимир Валентиновичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «14 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Вахитова** Миләүшә Әхәт кызына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү мәктәп-интернаты укытучысы **Володина** Алёна Игоревнага, Казан шәһәре Вахитов районының «Каюм Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 80 номерлы татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Сабирова** Ләйлә Гомәр кызына, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирелә торган 155 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Сафиуллина** Гөлназ Наил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Ватан хакына

Җиңеп кайтасыларына ышаныйк

Актаныш районының Киров авылында гомер итүче Венера Сабитованы тәрбиягә күп бала алып үстерүче ана буларак беләбез. Ире Алмас белән 9 ятимне җылы ояларына сыендырганнар. «Ватаным Татарстан» газетасы оештырган «Бу – минем туган авыл!» бәйгесендә дә җиңгәннәр иде. Алар һәр эштә актив. Сабитовлар балалары белән бергәләп махсус хәрби операциядә катнашучыларга күчтәнәч тә әзерлиләр, кирәк-яраклар да юллыйлар икән.

Күптән түгел Венера апа Мәскәү госпиталенә – яраланып, шунда ятучы авылдашы Альберт Җиһангиров янына да барып кайтты, анда дәваланучы егетләргә дә күчтәнәчләр илтте. «Госпитальгә килеп кергәч, Альберт бик сөенде. Актанышта гына пешерелә торган чәкчәк, ипи алып бардым», – дип искә ала Венера апа.

Табиблар, шәфкать туташлары белән сөйләшеп кайткач, ул шунда дәваланучыларга кирәк-ярак җыя башлый. Барлык авыл халкын кузгата. Тагын ике тапкыр бара әле ул Мәскәүгә. Башта 100 пакет күчтәнәч илтеп кайта. Аннан дус кызы белән тагын 50 пакет алып баралар.

– Мәскәү янәшәсендәге өч госпитальдә булдык. Анда эшләүчеләргә сокланып кайттым, – ди Венера Сабитова. – Табибларның эше җиңел түгел. Госпитальнең хирургия бүлегенә бардык бит. Анда яралылар күп иде. Төрле хәлдәгесе бар. Кемдер елмаеп эндәшә, ачулылары да бар, күңел төшенкелегенә бирелгәннәре дә. Алар белән психологлар эшли, диделәр. Егетләрнең үзләре белән бик сөйләшмәсәм дә, бик тетрәндем инде. Алар да – кемнеңдер газизе бит, без тыныч яшәсен өчен тырышалар.

Тиктомалдан гына хәрбиләргә булышып йөрми икән Венера ханым. Ятимлек ачысын бергә татыган иң газиз кешесе – бертуганы махсус хәрби операциядә катнаша.

– Әниебез бик иртә үлде. 39 яшендә фаҗигале төстә арабыздан китеп барды. Миңа – 13 яшь, иң кечкенәбезгә 7 генә тулган иде. Олы энем белән мине бер туганыбыз алып үстерде, кечкенә энебезне башкалары тәрбияләде. Ятимлекнең ачысы бик авыр иде. Иң кирәк чакта әнисез калдык. Җитмәсә, ул чакта әти дә безнең янда була алмады. Балачактан рәхәт күрмәдек, – дип сөйли Венера апа. – Узган елның сентябрендә энем Альберт СВОга китәсен әйтте. Авылда әти-әни йортында яши иде. Хатыны белән аерылышуны авыр кичерде, шул да сәбәп булгандыр. Ярый әле балалары әтиләре белән аралашып торалар.

Энесе Альберт Рәшитовка 52 яшь икән инде. Әле менә шушы көннәрдә ялга кайткан булган.

– Аны озатып җибәрүдән дә авыры юк, – ди Венера апа. – Мин энеләремә әни дә, апа да булырга тырыштым. Без – өч бөртек туган. Бер-беребезгә бик кирәкбез, кадерлебез. Нинди генә хәлләр килеп чыкса да, авырлыкны бергә күтәрәбез. Язмышка риза булып яшим. Энемне махсус хәрби операциягә озату да минем өстә иде. Хатыны булмагач, бар кирәк-ярагын үзем хәстәрләдем. Сумка тутырганда, йөрәкләрем өзгәләнде. Утырып еладым да. Бар гомерем күз алдыннан узды. Бер дә җибәрәсе килми. Энем гел элемтәгә чыга алмый. Землянкада яшиләр. Анда телефон да тотмый. Бик сирәк кенә сөйләшеп була. Ул хәбәр бирмәгән көннәрне башта меңуй инде.

Венера Сабитова фикеренчә, без андагыларга терәк булырга тиеш. Иң мөһиме – ир-егетләр көтәр кешеләре барын белеп торсын.

– Язмышларга язылганны үтәрбез. Эчәр сулары, ашар ризыклары бетмәсен, дип телим. Энемнең кайтуын бик көтәм. Исән-имин генә йөрсен, – ди Венера апа. – Җиңеп кайтасыларына ышаныйк. Илләр-көннәр тынычланса иде дип телик. Һәркем үз газизен көтеп алсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:
«АВЫРЛЫКЛАР ИГЪТИБАРЛЫРАК БУЛЫРГА, ТӨПТӘНРӘК УЙЛАРГА ГЫНА МӘҖБҮР ИТӘ»

Россия Президенты Владимир Путин февраль ахырында Федераль Җыенга Юлламасында төбәкләрнең бюджет кредитлары буенча бурычының өчтән ике өлеше кичереләсен әйтте. Татарстан финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИН белән шул хакта, гомумән, республиканың дәүләт бурычы, кредит рейтинглары хакында сөйләштек.

:: Радик Рәүфович, сүзне Президент Владимир Путинның федераль кредитлар буенча бурычның өчтән ике өлеше кичереләсе турындагы белдерүеннән башлыйк әле. Республика өчен ни дәрәҗәдә мөһим бу?

– Иң элек республикабызның федераль хакимияттә алданрак кабул ителгән һәм республика бурычын киметү мөмкинлеген күздә тоткан карарны тормышка ашыруда актив катнашуы турында берничә сүз әйтәсем килә.

:: Россия Хөкүмәтенең 1704 һәм 1740 нчы карарларын күздә тотып әйтүегезме?

– Әйе, сүз нәкъ менә шул хакта. Татарстан, федераль бюджетка бурычны реструктурлаштыру кысасында, 2020 һәм 2021 елларда кайбер яңа инвестицион проектларны тормышка ашыруны тәэмин итәр өчен инфраструктурага билгеле бер күләмдә акча кертүне үз өстенә алды. Әлеге проектлар федераль дәрәҗәдә хупланды. Шушы механизм кысасында, бу проектлардан федераль бюджетка өстәмә салым кереме күләмендә, элегрәк алынган бюджет кредитлары буенча бурычның бер өлешен гамәлдән алу күздә тотыла. Бүгенгә әнә шул рәвешле федераль бюджетка 9,6 миллиард сумлык әҗәт сызылды. Әлеге механизмның алга таба да тормышка ашырылачагын көтәбез.

:: Ә инде Федераль Җыенга Юлламада билгеләп үтелгән карарга карата нәрсә әйтә аласыз?

– Бу карарның Россия төбәкләренең финанс хәленә уңай йогынты ясаячагына шик белдерүче булмас, дип уйлыйм. Шул ук вакытта хәзер барыбыз да Россия Хөкүмәтенең бурычны кичерү тәртибен һәм кагыйдәләрне эшләвен көтә. Республикага килгәндә, без дә яңа механизмны гамәлгә ашыруда катнашуга өметләнәбез. Күп нәрсә Президент карарын үтәү барышында килеп чыгарга мөмкин булган нечкәлекләрдән торачак. Әлегә булган мәгълүматларга караганда, яңа механизм киләсе елдан гамәлгә кертелә.

> Төбәкләрнең федераль кредитлар буенча бурычының бер өлешен яңа механизмга кертмәячәкләр. Шул ук вакытта кичереләчәк бурыч күләмен инвестицияләр һәм инфраструктура проектларына юллау шарты тәкъдим ителә.

Кабатлап әйтәм: барысына да ачыклык кертү өчен Юлламада игълан ителгән карарны үтәү кагыйдәләре һәм тәртибенең федераль дәрәҗәдә кабул ителүен көтәргә кирәк.

:: Хәзерге вакытта республиканың дәүләт бурычы күпме? Шул хакта сөйләп үтсәгезче.

– 1 мартка республиканың гомуми бурычы 125,5 миллиард сум тәшкил итә. Шуның 115,9 миллиард сумы – федераль бюджет кредитларына, 9,6 миллиард сумы дәүләт гарантияләренә туры килә. Әйтергә кирәк, узган елда тиешле өлкәләрдә объектлар төзү һәм капиталь төзекләндерү өчен, «Торак», «Заманча мәктәп», «Мәдәни мохит», «Сәламәтлек саклау өлкәсенең беренчел буынын модернизацияләү», «Төбәк һәм җирле юллар челтәре» федераль проектларын тормышка ашыру кысасында республика чыгымнарына акчаны алдан ук биреп кую максатында алынган бюджет кредитлары буенча 15 миллиард сум чамасы бурыч апрель ахырына кадәр түләнергә тиеш. Бу бурыч федераль бюджеттан бюджетара трансфертлар хисабына каплана.

:: Әлбәттә, зур күләмдәге акча турында сүз бара. Мәгълүм булганча, дәүләт бурычы күләме ягыннан без төбәкләр исемлегендә иң өстә торабыз. Бу хакта сезнең фикерегезне ишетәсе килә.

– Әйе, бурычның гомуми күләме буенча безнең күрсәткеч Россия төбәкләре арасында иң зурлардан берсе булып санала. Әмма биредә берничә әйберне исәпкә алырга кирәк. Беренче чиратта, инде моңа кадәр дә күп тапкырлар әйткәнемчә, хәзерге вакытта республиканың базар кредитлары буенча, ягъни банк кредитлары, дәүләт кыйммәтле кәгазьләре рәвешендәге бурычлары юк. Бурычны түләү чыгымнарын киметүгә бик уңай йогынты ясый бу. Гади итеп әйтсәк, процент түләү мәсьәләсе җиңелрәк. Банк кредитлары федераль бюджет кредитларына караганда кыйммәткәрәк төшә.

> Дәүләт бурычы күләменә килсәк, аны республика бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләме белән чагыштырып карарга мөмкин. Бу керем узган елда 407,2 миллиард сум тәшкил итте. Әлеге күрсәткечләрнең нисбәте – 31% чамасы. Ә бу, Россия Финанс министрлыгы бәяләмәләре буенча, кулай күрсәткеч булып тора.

Гомумән, федераль дәрәҗәдә Россия субъектларының бурыч түләүгә сәләтен бәяләү кысасында, Татарстанның даими рәвештә әҗәтне җиңел түли торган төбәкләр төркеменә кертелүен искәртеп узарга кирәк.

Шунысы да бар: федераль бюджет кредитларын түләү вакыты шактый ук озын – 2038 елга кадәр. Башлыча бу, 2012 елдан башлап, федераль бюджетка озак сроклы бурычларны реструктурлаштыру эшен эзлекле төстә алып баруның нәтиҗәсе булып тора.

:: Быел илебезнең төп кредит рейтинг агентлыкларының республикабызны уңай бәяләве тикмәгә генә түгел, димәк.

– Россиянең «Эксперт РА» һәм «АКРА» («Аналитик кредит рейтингы агентлыгы») рейтинг агентлыклары белән хезмәттәшлекне дәвам иттерәбез. Узган елның декабрендә һәм быел февраль аенда алар Татарстанның кредит рейтингларын раслады. Әйтергә кирәк, Россиядә кулланылып килүче иң зур шкала буенча. Рейтинг агентлыклары билгеләп үткәнчә, төбәк икътисадын үстерүдә чагыштырмача югары күрсәткечләр, инвестицияләр өчен әйбәт шартлар, бюджетны балансны үтәү һәм республика дәүләт бурычы мәсьәләсендәге тотрыклылык кебек күрсәткечләр республиканы бәяләүгә уңай йогынты ясаган.

Һичшиксез, геосәяси процесслар, Көнбатыш дәүләтләре ягыннан Россиягә карата санкцияләр һәм административ чикләүләр кысасында, бүгенге этапта республиканың һәм тулаем илнең социаль-икътисадый үсешенә югары дәрәҗәдә билгесезлек хас. Әмма боларның барысы да, гомумән алганда, республика бюджетын формалаштыру һәм үтәү мәсьәләләрендә, аерым алганда, дәүләт бурычына бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә безне тагын да игътибарлырак булырга, төптән уйларга гына мәҗбүр итә.

ИКЕСЕНӘ БЕР ҺӨНӘР

Сак булыгыз: ут!

Саба районының Ике Басу Арташы егетләре – бертуган Фәнис һәм Данис Сәлахиевлар Иске Икшермә янгын сүндерү хезмәтендә эшли. Шунысы кызык: гаиләдәге биш егетнең дүртесенең дә (!) коткаручы булып эшләп караганы бар.

«Карактан кала, уттан берни дә калмый», – диләр. Әлеге егетләрнең үз гомерендә янгыннарның ниндиен генә күргәне юк. Арада кеше гомерен саклап калганнары да, коткара алмаганнары да бар. Кайбер утлы вакыйгалар, еллар үтсә дә, онытылмый. Фәнис 24 ел эчендә 400дән артык янгында катнашкан. Хәзер инде ул Иске Икшермә янгын сүндерү хезмәтен җитәкли. Аның карамагында – 10 кеше. Данис исә сигез елга соңрак килгән.

Иске Икшермә бүлекчәсенә 11 авыл керә. Янгын сүндерүчеләргә көн дә, төн дә юк. Постка хәбәр килеп ирешүгә, янгын чыккан авылга 20 минут эчендә барып җитәргә кирәк. Күрше районнарга да булышырга барырга туры килә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бертуган Фәнис (фотода сулда) һәм Данис Сәлахиевлар үз эшләрен яратып башкара.

Үкенечләр

2010 елда ике бертуган үзләре дә ут корбаны була язган. Егетләрне июнь аенда Теләче районы урманына чирәм сүндерергә җибәргәннәр. Тик җил чыгып, мизгел эчендә ялкын бар җирне камап алган. Утлы капкыннан көчкә котыла алар. Хәл беткән, сулыш кысылган… Тик шуңа карамастан, янгынны сүндереп кайталар.

2013 елда Кибәче авылында иртүк янгын чыга. Кыздырган табага, май дип, ялгыш бензин салганнар. Шулай итеп, шешәләр буталган. Бу вакытта гаилә башлыгы абзарга мал-туар карарга чыгып китә. Өйдә каенана белән килен кала. 112 хезмәтендәгеләр вакытында килеп җитсә дә, кызганыч, аларны коткарып кала алмыйлар.

Дус, туганнар йортына кайгы килгәндә, бару җиңел түгел. Бервакыт: «Бәдәр әбиләрегезнең өе яна!» – дип хәбәр итәләр. Мондый очракларда хискә бирелергә ярамый. Янгын сүндерүче өчен бар кеше дә бертигез.

Теләк

Егетләрдән икесенең дә бер һөнәрне нигә сайлавы турында сораштык. Әйткәнемчә, энекәшләре Нәфис белән Рафисның да әлеге өлкәдә эшләп караганы бар. Әмма алар хәзер башка юнәлештә хезмәт куя.

– 2001 елда Екатеринбургка янгынга каршы хезмәт академиясенә укырга керергә барган идем. Математика белән физкультурадан имтиханны тапшырдым, тик рус теленнән изложение яза алмадым. Шуңа күрә кире борылып кайтырга туры килде. Әмма күңелемне төшермәдем. Сабадагы янгынга каршы хезмәт күрсәтү отрядына эшкә урнаштым. Миңа ул чакта 17 яшь иде. Хезмәткә физик яктан сынап, имтихан тапшыртып алдылар. Тугыз айдан соң армиягә киттем. Энем Данис белән Самара өлкәсендә бергә хезмәт иттек. Яшь аермабыз – бары бер генә яшь. Хәрби хезмәттән кайткач, эшемне дәвам иттердем. Анда тугыз ел хезмәт куйдым. Аннан Иске Икшермә бүлекчәсенә җитәкче итеп күчерделәр, – ди Фәнис Сәлахиев.

Әлбәттә, абыйсының янгын сүндерүче булып эшләве Данисны да кызыктырган. Аңа охшарга тырышкан. Кыюлык бар, ә нигә сынап карамаска?

– Кечкенә чакта кешеләргә булышырга ярата идем. Безне әти-әни, әби-бабай шулай тәрбияләде. Әтиебез Фаяз – әфганчы. Әбиебез Бәдәр – үзе бер кыюлык үрнәге. Медицина белеме булмаса да, авылдагы йөзләгән малайны сөннәткә утырткан ул. Без – биш туганны да сөннәтләде, – ди Данис, горурлык белән. Армиядән кайткач, башта колхозда тракторчы, аннан җиһаз ясаучы, төзүче булып эшли. Тора-бара агач эшкәртү буенча үз бизнесын ачкан. Хәзер инде ул – тәҗрибәле янгын сүндерүче.

Янгыннарның килеп чыгуына күп очракта саксызлык гаепле. Ут-күз коры вакытка караганда, ягу сезоны башлангач, октябрь, ноябрьдә ешрак чыга икән. Ни өчен дигәндә, өстәмә җылыткычлар куялар.

– Атна буе торган 40 градус эсселәрне дә тыныч кына үткәрәбез. Көтмәгәндә чыга ул афәт. Күп очракта электр приборларын саксыз куллану, калай сэндвич торбалар сәбәпче моңа. Әлеге торбаларны утын мичләренә куярга тәкъдим итмибез. Алар тиз туза, кулланыш вакыты 2–3 ел гына, – ди бүлек җитәкчесе.

Кисәтү

Узган ел әлеге тирәлектә биш янгын теркәлгән. Аңа кадәрге елларда аларның саны 2–3 иде. Бөтенләй булмаган еллар да бар.

– Янгын куркынычсызлыгына бәйле чаралар күп. Әби-бабайлар, ялгыз яшәүчеләрнең өйләренә барабыз. Мәктәпләргә барып аңлатабыз. Шырпы белән шаярган балалар юк хәзер, – ди Фәнис Сәлахиев.

Аның әйтүенчә, янгынга кадәр барып җитмәгән очраклар да бар. Йортларга автоматлаштырылган сигнализация җиһазлары урнаштыру файдасы бу. Ул, төтен керүгә, кычкыра башлый. Районда өлкәннәргә социаль программа буенча куйдырткannar. «Бәясе – 300 сум тирәсе. Өйгә берничә урынга куярга кирәк», – дип киңәш итә.

Сүзгә Данис кушыла: «Буржуйкалар өйдән 20 метр еракта булырга тиеш. Кайберәүләр шуны өй, абзар тирәсенә үк куя. Гадәттән тыш хәлләрнең күбесе шундый вак кына әйберләргә бәйле. Әйткәч, үпкәләүчеләр, аңламаучылар да бар. Гомер буе җыйган малыгызны биш минут эчендә юкка чыгарасыз бит. Сак булыгыз!»

Сәрия МИФТАХОВА

ЯСАЛМА УКЫТУЧЫ

Яңа гасыр мәктәбе

Һиндстан дөньяны гаҗәпләндерде: Керала штаты мәктәбендә Iris исемле робот-укытучы дәрес бирә башлаган. Өстендә – укытучыга хас милли кием – җете сари. Биргән сабагы да аңлаешлы икән. Җитмәсә, өч телдә сөйләшә белә. Мондый роботлар безнең мәктәпләргә дә килеп җитмәсме? Алар чын укытучыны алыштыра аламы?


robotportal.ru

Робот ясалма интеллект базасында булдырылган. Ул сыйныф бүлмәсендә тәгәрмәчләр ярдәмендә хәрәкәт итә. Танышкан вакытта укучыларга кулын суза. Фән буенча төрле сорауларга да җавап бирә ала икән. «Iris ярдәмендә без, ясалма интеллект мөмкинлекләрен кулланып, һәр укучыга якын килеп, белем бирүдә революция ясарга ниятлибез. Робот укытучы дәресләрне кызыклы һәм файдалы итеп үткәрү мөмкинлеге бирә», – ди аны уйлап табучылар.

Якын киләчәктә робот укытучыларны мәктәпләрдә еш күрә башларбыз дип әйтү кыен. Әмма аны җәлеп итү тәҗрибәсе, ясалма интеллект мәгарифтә ярдәмче роль уйнаячак. Һәрхәлдә, роботны ясаучылар шундый фикердә.

Бу яңалыкка карата Татарстан белән Һиндстан арасында элемтәләрне үстерү үзәге җитәкчесе Әхмәд Иштиакның фикерен сораштык.

– Ясалма интеллект бу. Әлбәттә, кешене алыштыру әйбәт түгел. Без – тере җан, адәм баласының хис-тойгылары бар. Ләкин замана балаларының гаджет, компьютерларга өстенлек бирүен беләбез, – ди Әхмәд Иштиак. – Укып бетергәч, барысы да Гарвард яки Мәскәү дәүләт университетына керә алмый. Сәламәтлеге начаррак, аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр дә бар. Без балаларның барысына да тигез шартлар тудырырга тиеш. Шуңа күрә мин моны гадел карар дип саныйм. Дөнья мәктәпләрендә укытучылар җитми. Минем фикеремчә, киләчәктә һәр гаиләнең үз роботы булачак. Тормышта уңайлыклар бик мөһим. Ул аны яхшыртырга ярдәм итәчәк.

Педагоглар кытлыгы Татарстан өчен дә яңалык түгел. Яңа уку елы башында күпме кадр җитмәвен ел саен язып торабыз. Республикада 2022–2029 елларда педагогик белгечләргә булган ихтыяҗ-фараздан да күренә бу. Әйтик, 2024–2025 уку елына – 1079, 2025–2026 уку елында 985 укытучы кирәк булачак. Башлангыч сыйныф, математика, физика, химия, рус теле укытучыларына кытлык бар. Әгәр яшьләр, хезмәт хакы аз, әти-әниләр белән уртак тел таба алмыйбыз, дип мәктәпкә бармый башласа, пенсионер укытучылар китеп бетсә, «юк, бездә алай булмас» дип, кырт кисеп әйтеп булмыйдыр.

Сан

2022–2023 уку елында республика мәгариф системасына **900**дән артык педагог килгән. Шул ук вакытта **240**лап яшь укытучы эштән киткән.

Югары Ослан районындагы Иннополис лицеенда эшләүче, «Ел укытучысы – 2023» республика бәйгесе җиңүчесе Арман Костанян моны кызыклы идея дип саный.

– Әлегә нейрон челтәрләр бик гади дәрәҗәдә. Аларны ниндидер фикер йөртә, нәтиҗә чыгара белә торган чын ясалма интеллект дип әйтеп булмый. Шуңа күрә укытучыны робот берничек тә алыштыра алмаячак. Әмма аны дәрестә корал буларак кулланырга кирәк. Һиндстан мәктәпләрендә укучыларның бик үк укырга яратмавын ишетеп беләбез. Шуңа күрә укучыларның игътибарын укуга юнәлтү өчен әйбәт нәрсә. Ә инде укучы белән робот бергә-бер калудан ниндидер файдалы әйбер чыгар дип уйлмыйм, – ди Арман Костанян.

Мамадыш районының Олыяз лицеен заманча карашлы, яңа технологияләр уйлап табучы мәктәп буларак беләбез. Анда яшь физиклар хәтта токны бәрәңгедән, лимоннан ала белә. Кесә телефоны зарядка җыйсын өчен биш лимон җитә икән. Гөлгә су сибә торган автомат җайланма да – укучылар хезмәте. Укучыларның остазы – физика-математика укытучысы Зөлфәт Мурзин.

Зөлфәт Мурзин әйтүенчә, Олыяз мәктәбендә укытучылар җитә. Ул үзе – элеккеге инженер. Башта укучыларны техника йөртергә өйрәтсә, тора-бара технология, математика, физика фәннәреннән белемен күтәргән. Квалификация алыштырып, берничә фәнне укытучылар тагын бар әле. Авыл мәктәпләре менә шулай педагоглар кытлыгын хәл итәргә тырыша.

– Укытуны гел роботка гына тапшырып булмастыр дип уйлыйм. Без бит дәресне хисләр аша аңлатабыз. Тәрбия моменты да бар. Робот моны булдыра алмаячак. Белем алу өчен аны кулланырга була, минемчә. Балаларда укуга карата кызыксынуны арттырырга ярдәм итәчәк, – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Мин кулыма китап алам

Татар нәрсә укый?

Татарстанның Милли китапханәсе кыш айларына йомгак ясады. Декабрь башыннан алып февраль ахырына кадәр барлыгы 71247 китап укыганбыз. Аңлашыла инде, бу – китапханәдән алып укыган китаплар саны гына. Без исә иң популяр татар китапларына күз салыйк.

Гаяз Исхакыйдан алып Галия Сафиуллинага кадәр. Кыш айларында иң күп укылган татар китаплары исемлегендә әсәрләрнең төрлесе бар. Алар турында сөйләгәндә, бәяләрен дә күрсәтеп барырбыз. Татар китабы күпме тора? tatkniga.ru сайтындагы актуаль мәгълүматларга нигезләнеп, әнә шул сорауга җавап биреп карарбыз.

Унынчы урыннан – **Гаяз ИСХАКЫЙның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»** (1902) әсәреннән башлыйк. Кайчандыр татар тормышын сискәндереп җибәргән бу әсәр тема һәм проблема ягыннан да, укучылар игътибары ягыннан да һаман актуаль. *(Шул исемдәге җыентык 360 сум тора.)*

Тугызынчы урында – **Рифкать ИМАЕВның «Уйлы көнем»** (2017) шигырьләр җыентыгы. Заманында «есенинчы» мөһере сугылган химик-шагыйрьнең соңгы җыентыгы бу. *(Җыентыкны башка бер онлайн сату мәйданчыгында 490 сумга таптык.)*

Сигезенче урында – **Гүзәл ГАЛЛӘМОВАның «Зәңгәр кыңгыраулар»** (2020) романы. Бу китапны авылда егылып укулары турында ишетеп килгән идем, бу исемлеккә дә кергән икән. «Әсәрдә вакыйгалар бик тиз үз эченә алып, укучыда көчле рух тәрбияли, мәңге изге әхлакый төшенчәләрне олыларга чакыра, ахирәт тормышын искә төшерә», – дип язылган аннотациядә. *(Бәясе – 595 сум.)*

Фәүзия БӘЙРӘМОВАның «Һиҗрәт» (2017) тарихи романы – җиденче урында. «Роман узган гасыр башларында ислам дине хакына Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр булган милләттәшләребез турында», – ди автор үзе әлеге китабы турында. *(Бәясе – 390 сум.)*

Зифа КАДЫЙРОВАның «Бәхеткә юл кайдан?» (2013) әсәре алтынчы урынны алган. Авторның: «Башкалар ялгышы гыйбрәт булсын», – дигән теләктә язылган, берничә гаилә турындагы хикәятләрне берләштергән романнарының берсе. Бу авторга тагын бер әйләнеп кайтырбыз әле. *(510 сум тора.)*

Бишенче урында исә **Галия САФИУЛЛИНАның «Сыналган мәхәббәт»** (2020) китабы урнашкан. Бу әсәр турында: «Кешене кеше итә, аңа яшәргә, эшләргә көч, өмет бирә торган иң якты хисләрнең берсенә – ярату хисенә багышлана», – дип язалар. *(480 сумга сатыла.)*

Дүртенче урында янә үлмәс классика – **Әмирхан ЕНИКИнең «Матурлык»** (1964) хикәясе. Бу әсәр турында ни дә булса язарга кирәкме икән? Аны барыбыз да белә, укыган саен укып туймый кебек. *(Шушы исемдәге хикәяләр, повестьлар җыентыгы 150 сум тора.)*

Өченче урында янә таныш автор – **Галия САФИУЛЛИНАның «Заһидә»** (2021) повесте. Чирмешәндә яшәп иҗат итүче язучының бу китабы да «давыллы-буранлы язмышлар» турында. *(480 сумга сатыла.)*

Икенче урында – **Зифа КАДЫЙРОВАның «Урланган яшьлек»** (2022) китабы. «Урланган яшьлек» һәм «Кем каргады?» повестьларын берләштергән җыентык ул. Бу әсәрләрдә дә, авторның башка китапларындагы кебек, төп геройлар – халык арасыннан чыккан, катлаулы тормыш юлын узган кешеләр. *(510 сум тора.)*

Кыш айларында иң күп укылган татар китабы – **Ринат МӨХӘММӘДИЕВнең** ике әдәби-документаль романны үз эченә алган **«Ак кәгазь нидән саргая»** җыентыгы. «Ак кәгазь нидән саргая» романы узган гасырның егерменче-утызынчы елларындагы татар зыялыларының аянычлы язмышын сурәтләсә, «Утлы таба өстендә» романы авторның үз башыннан кичкән вакыйгаларга нигезләнә. *(Онлайн мәйданчыкларда ул китапны таба алмадык.)*

***

Мәхәббәт һәм аянычлы язмышлар турындагы романнарның күп укылуы – яңалык түгел, билгеле. Мондый тенденция, гомумән, дөнья буенча күзәтелә. Ә күп укылган китаплар унлыгына тарихи һәм документаль жанрларның да керүенә сөенмичә булмый.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Илдар Мөхәммәтҗанов

Соклану

ЙӨРӘК АША УЗГАН ГОМЕР


nurlat-tat.ru

Илдус абый Диндаров белән танышуым туган ягымда – Яңа Чишмә районының Чертуш авылында 2019 елда булды. Авылга кергәндә, юлның уң ягындагы калкулыкта Туганнар каберлеге тора. Гражданнар сугышы елларында кызыл мадьярлар тарафыннан атып үтерелгән утыз җиде карт җирләнгән бирегә. Һәм менә шул канлы вакыйга уңаеннан шәһитләрне искә алу чарасы үткәрелде Чертушта. Шунда мин төбәк тарихчысы, күренекле публицист буларак тәкъдим ителгән Илдус абыйга игътибар итеп калган идем.

Кулында – үзенең саллы китабы, телендә – илкөн гаме. Сүзгә кесәгә керми торган белемле, фәһемле шәхес. Мин аның әле республика газета-журналларының даими авторы, «Ватаным Татарстан» газетасының Нурлат – Чирмешән төбәге буенча үз хәбәрчесе булуын да, Нурлат шәһәренең мактаулы гражданины, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Бәллүр каләм» иясе икәнен дә белми идем ул вакытта. Тормыш букчасында әдәби хезмәткәр, мөхәррирлек вазыйфалары булуын да, дистәләгән китап авторы икәнен дә соңрак белдем. Анысы «Мәйдан» журналында эшләгәндә, Илдус Диндаровның «Кәшифулла грантлары», «Нурлат мәзәкләре»н бастырган чакта булды. Күзәтүчән кеше; тормышның агын да, карасын да күргән, хәзер инде дөньясына бераз юмор-сатира белән карарга өйрәнгән кеше, дип уйлаганым хәтердә.

Соңрак кулыма авторның култамгасы белән «Кояшлы көннәрем, айлы төннәрем» китабы килеп керде. Китапка сүз башы язган Гәрәй ага Рәхим «Күңелгә ятышлы шигърият» дип бәяли аның шигъриятен. «Җиңел агышлы шигырьләрен укыганда, дөрестән дә, күңелгә яктылык сирпелгәндәй, илаһи нур яткандай була. Ул, туган телнең сүз тәмене, кодрәтенә, аһәңенә, сыгылмалыгына соклана-соклана, күңеленә хуш килгән, беренче карашка гадәти, гади, әмма гали, бөек, мәңгелек темаларга мөрәҗәгать итә, шулардан туган хисләрен, фикерләрен шигырь итеп үрә», – ди ул.

Мин дә маңгай күзе белән күреп тә, күңел күзе күрмәгән дөньяны Илдус абый шигырьләре аша ача барам.

«Тын кичләрдә ак түшләре белән
Агачларның орынып очына,
Яшь алмашның көчен сыный-сыный,
Карлыгачлар бала очыра», –

дип башлана менә бер шигыре. «Канат читен күл суына манып» очынган карлыгачларга карап, ни өчен «күккә карап уфтаналар картлар»? «Ерак юлга җыенырга вакыт» җитеп килә икән ләбаса. Инде үз «карлыгач»ларының бала багуын күзәтә олы-кара. Күңелдә әллә никадәр теләк-хыяллар булса да, «әмма инде күңел юашланган – карлыгачлар бала очыра»…

Якты сагышлы моңы белән үз эченә алып кереп киткән лирик шигырьләреннән соң Илдус Диндаровның мәсәлләрен уку минем өчен тагын бер ачыш булды.

Нинди генә жанрда, нинди генә темага язмый ул! Гыйбрәтле тормыш-көнкүреш хәлләреннән булсынмы, инде җәмгыятьтә шактый тамыр җәя барган берәр ямьсез сыйфат уңаеннанмы – һәрнәрсәне фәлсәфи күзлектән күзәтә автор, хикмәтле сүзен әйтә, үткен итеп нәтиҗә чыгарып куя.

«Көнчелек бәласе», «Көрәк һәм сәнәк», «Тышау», «Өй чикерткәсе – шөрчек», «Тәрәзә белән Көзге», «Тукран» һәм башка мәсәлләр дә гади, халыкчан тел белән язылган, шул ук вакытта әхлакый фикер күңеленә сеңдерерлек итеп әйтелгән.

Узган ел исә Казанда зурлап Саҗидә Сөләйманова премиясен тапшыру тантанасында булырга туры килде. Лауреатлар арасында танылган журналист, публицист, язучы, шагыйрь Илдус Диндаровның да булуына сөенеп утырдым. Миңа калса, күптән әллә нинди мәртәбәле исемнәргә ия булырлык иҗат әһеле ул. Башкалага якынрак яшәсә, бәлки иҗатына игътибар зуррак булыр иде дип тә уйлыйм. Бигайбә, казанда пешкән майлы калҗалы шулпаның исе шул казан тирәсендәгеләрнең борынын гына кытыклый – сыйга читтәгеләр еш чакырылмый.

Ә премия повесть, хикәяләр, юморескалар, публицистика тупланган «Торна күзе» китабы өчен бирелде. Бу уңайдан Чулман аръягы мәдәни-рухи тормышына зур ярдәм күрсәтүче «Рухият» фонды нәшриятын әйтеп китми булмый. Бик күп каләм әһелләрен укучысы белән очраштырды ул. «Торна күзе» китабына кергән әсәрләргә карата Фәйрүзә апа Мөслимова «Йөрәк белән язылган» дигән билгеләмәсен биреп калдырган. «Хикәяләре аша мин Илдусның гаять тә нечкә күңелле, шигъри хисле булуын, үзе сурәтләгән геройларының тормыш хәлләрен йөрәге аша сызланып кичерүен тойдым», – дип язган үзе дә үтә нечкә хиссиятле шагыйрә.

Әйе, хикәяләрендә шагыйранә йөрәкле, «Каршылыклар кыры» повестенда тормышның армия дигән сыналу урынының бөтен нечкәлекләрен белгән кырыс реалист та автор.

Илдус Диндаровның соңгы елларда еш үткәрелә башлаган ябык бәйгеләрдә җиңүчеләр арасында булуына да гаҗәпләнмим мин. Аларның балалар һәм яшүсмерләр өчен әсәрләр булуына гына сокланам. Җитмеш биш яшен тутырып килгән, дөнья күргән аганың яшь буынга җиткерәсе сүз-нәсыйхәтләре әсәр буларак тупланган икән – бик хуп бу. Узган ел Роберт Миңнуллин исемендәге әдәби конкурста аның балалар өчен «Йомгак кая качкан?» шигырьләр циклы икенче урынга лаек дип табылды. 2021 елда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән әдәби конкурсның «Үсмерләр өчен повесть» номинациясендә «Ак төннәрнең кара көннәре» повесте өченче урынны алды. Соңгысына бераз күбрәк тукталасым килә.

Әсәрне укый башлауга, Хәниф Хәйруллинның «Киржаклар илендә» әсәре исемә төште. Дөньяның әлегә кадәр билгеле булмаган якларын танып белү – бала күңеленең иң көчле мотиваторы бит ул. Дөрес, Кызыл Таңнан Карелия – Ленинград тарафларына гына кебек бу юл. Ләкин нинди юл бит!

Әсәрнең төп герое Гафур төрле яклап ачыла безгә: авылдагы дусты Сөббух, карел малае Ваассила, мордва кызы Гелия аша да, әнисе Өммегөлсемгә, ач Ленинград урамында калган табылдык кызчыкка мөнәсәбәтендә дә ачыла ул. Балык тоту, яңа җирләр белән танышу теләге иң зур теләк булган кызыксынучан малайның ачлык, суык, сугыш афәтләрен күргән, нәни сеңелкәшен югалткан, ачлыктан хәлсезләнгән, аягы яраланган әнисенә ничек тә ярдәм итәргә тырышкан вакытыннан алда ирләрчә ныгып киткән үсмергә әйләнүен күрәбез.

Язучының үзе сурәтләгән хәлләр турында яхшы белүе, бу хәлләрнең хыял тудырган вакыйгалар гына булмавы укучыга бик яхшы аңлашыла. Совет – фин сугышыннан соң кушылган карел җирләренә Татарстаннан, Тамбов якларыннан вербовка белән татар гаиләләрен дә күчереп утырталар. Татарча атамалы колхоз оештырып, күченеп килүчеләргә үз ана телләрендә укырга мөмкинлекләр дә булдырылган икән хәтта. Ел ярым чамасы яшәгәннән соң сугыш башланган, тормышның асты өскә килгән…

Тормышны яратып, тәмле итеп, мәнле итеп яшәүчеләр була. Алар, гадәттә, үзләренә дә, тирә-юньдәгеләргә дә, дөньяга да битараф түгел – гаделсезлекләрне фаш итеп, көрәшеп-янып, матурлыкны арттырырга омтылып яши.

Гомер юлының шактые узылгач, Илдус Диндаровча уфтанып та куядыр:

Әллә ничек кенә үтте гомер:
Каралама калган язма күк.
Акка күчерергә өлгермәдек,
Хисап бирер вакыт: алда – Күк!

Караламада язылганнар йөз кызартырлык булмасын – күкләр өчен дә, кешеләр өчен дә иң мөһиме шулдыр.

Ә Илдус абый Диндаровның эшләгән эшләре, иҗат иткән әсәрләре буенча фикер йөртсәк, караламага да пөхтә кул белән, уен уйдырып, намус кызармаслык итеп язган ул. Киләчәктә дә аңа бәрәкәтле, иҗади, гамьле гомер еллары насыйп булсын.

Лилия ФӘТТАХОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, әнисе
САВЕЛЬЕВА Анна Ивановна
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Экспертлар департаменты җитәкчесе Савельев Игорь Леонидовичның авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе
САВЕЛЬЕВА Анна Ивановна
вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Экспертлар департаменты җитәкчесе Савельев Игорь Леонидовичның авыр кайгысын уртаклаша.

ДУГА УРТАСЫНДАГЫ ТОРМЫШ

Без бел(мә)гән тарих

Казан каймасын мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү буенча әзерлек эшләре башлану турындагы хәбәргә, мөгаен, беренче чиратта кайбычлылар шатлангандыр. Күптәнге хыяллары иде ул аларның. Ни дисәң дә, вакыт үткән саен, җирдәге эзләр югала бара, шуның белән Җиңүгә саллы өлеш керткән окоп казучыларның эшләре дә хәтердән җуела. Шуңа бик борчылдылар.

Киләчәк буын өчен кирәк...

Кайбыч районы башлыгы урынбасары Рамис Хәялиев бу сүзләрне миңа инде шактый еллар элек, окоп казучыларның батырлыгын барлап йөргәндә әйткән иде. Сүз белән генә калмады, әлбәттә. Моннан берничә ел элек Дәүләт Советының бер утырышында, шушы теманы күтәреп, саллы гына чыгыш та ясады.

– Ул вакытта чыгышымны бик кирәклегә санап, «каләм очына» алганнар иде, – ди Рамис Рафисович. – Гел бер сүзне кабатлап торып булмый. Онытылар, ахры, дип тә уйлаган чаклар булды. Менә, ниһаять, боз кузгалды. Кызганыч, без бу эшкә соңрак та калдык бугай. Окоплар белән кызыксыну 2000 нче елларда гына башланды. Ни өчен шулай килеп чыкканын әйтә алмыйм. Югыйсә сер итеп тә сакланмады бит ул. Иң төп сәбәп – мөгаен, битарафлыктыр. Хәтерлим: узган гасыр ахырында һәр өйдә диярлек окоп казучылар исән иде әле. Хәзер берничә генә кеше калды инде. Районда бу темага ел саен фәнни конференция уздырыла. Анда күрше районнардан, хәтта башка республикалардан да катнашалар. Казан каймасына багышлап, Олы Кайбыч һәм Иске Чәчкаб авылларында һәйкәлләр тәзедек. Илебез тарихында тиңе булмаган бу хезмәт батырлыгын чагылдыру өчен болар гына җитми иде, әлбәттә.

Ни өчен Кайбычта?

– Казан каймасының 60 чакрымы Кайбыч районына туры килә. Аннан килеп, окоп эшләре бездә яхшырак та сакланган, – ди бу җәһәттән Рамис Рафисович. – Дошман безгә килеп җитмәс дигән бер генә ышаныч та булмаган. Бу зур оборона сызыгының максаты – дошманны Идел буенда туктату, Урал сәнәгать зонасына җибәрмәү. Өстәвенә Казан, Яшел Үзән шәһәрләренә Мәскәү белән Ленинградтан иң мөһим сәнәгать предприятиеләре эвакуацияләнә.

Шунысын да әйтик: бу окоплар Татарстанда гына түгел, ә Идел буендагы башка шәһәрләрдә дә казыла. Ул Идел буе оборона сызыгы дип атала. Гомуми озынлыгы ике мең чакрымны тәшкил итә. Объект дуга формасында булганлыктан, халык аңа Казан каймасы дип исем бирә. Кайбыч тирәсендә оборона сызыгы аеруча зур нигытмалар белән төзелгән. Монда гади халык белән бергә саперлар да эшли. Туң җирне шартлату, инженерлык хезмәте югары дәрәҗәдә оештырыла. Немец танклары килеп җитсә, дуганың уртасына һөҗүм итәрләр дип фикер йөрткәннәр. Чөнки бу урында элек тә Мәскәү юлы булган. М12 трассасы да нәкъ шушы Иске Чәчкаб, Олы Кайбыч янәшәсеннән уза. Казан каймасының беренче номерлы төзелеш штабы Иске Чәчкаб авылында урнаша. Шуңа күрә бу эшләр Кайбыч районында кискенрәк төс алып, эзләре дә тирәнрәк калган.

– Мин үзем дә шушы авылдан, – ди Рамис Рафисович. – Халык телендә окоплар дип аталган бу чокырларда күпме буын малайлар уйнап үсте. Әти-әни, әби-бабайлар да бу хакта гел искә төшереп, сөйләп торды.

Һәр йортка кагыла

Окоп казу эшләре нигездә хатын-кызларга бәйле. Нинди генә шартлар булуга карамастан, окоп казылган районнарда гаиләдән бер кеше кулына көрәк алып, мәҗбүри төстә эшкә чыгарга тиеш булган. Төзелешне башлау турындагы боерык 1941 елның октябрь аенда кабул ителә. Шундук Татарстанның шәһәр-районнарыннан эшчеләр килә башлый. Мобилизация бик көчле оештырыла.

Штаб урнашкан Иске Чәчкаб авылында бөтен Татарстанга танылган иҗат әһелләре дә эшли, башкалар кебек, туң җир казый. Алар арасында Гомәр Бәширов та була. Бригадирлары – Гадел Кутуй. Авыр эштән арып кайткан көннәрнең берсендә ул композитор Җәүдәт Фәйзигә мөрәҗәгать итә. «Гел болай күңелсезләнеп йөреп булмый бит инде. Күңелне күтәрә торган берәр әсәр язасыңмы әллә?» – ди. Бу фикер бик тиз тормышка аша. 1942 елның 1 мартында, окоплар казуны тәмамлап кайтуга, әле бүген дә сәхнәдән төшмәгән «Башмагым» музыкаль комедиясенең премьерасы була. Гадел Кутуй үзе дә кичләрен иҗат белән шөгыльләнә. Килгәч тә, юлда күргән мәхшәрләр турында «Юл газабы» дигән шигырь яза. Күршесе куыксыз лампа кертеп биргәч, «Сукыр лампа» шигырен иҗат итә.

Сан

Планда төзелешкә **37** районнан **300** меңгә якын кеше җибәрү каралa. Якындагы Буа, Апас, Норлат (хәзер Яшел Үзән районы составына керә) **10**ар мең кеше җибәрергә тиеш була. Ераграк районнарга норма азрак бирелгән. Мисал өчен, Балтачка – **3** мең, Чепьяга – **2** мең кеше. Казанга **83** меңнән артык эшче җибәрү бурычы куела. Әмма бу норма үтәлми.

Килеп төшүчеләр арасында салкыннан авырып китүчеләр, үлүчеләр дә була. Качып китү очраклары да теркәлә. Төзелештә даими рәвештә 100 мең тирәсе кеше эшләгән. Казан дәүләт университеты һәм башка уку йортлары тулысынча окоп казырга җибәрелә. Университет ректоры Кирилл Ситников үз барышы белән шәхсән җитәкчелек итә.

Эшкә килгән халык, тирә-як авылларга таралып, шәхси йортларда күмәкләшеп яши. Җирле халыкның өе кысан булса да, күңеле киң була. Әбибабай мич башына, бала-чага сәндерәгә күчә. Фатирга кергән халык, салам җәеп, идән тутырып йоклый. Өс һәм аяк киеме, ашарга ризык, ягарга утын, эш кораллары җитәр-җитмәс кенә була. Әбәт ашатырга кухня әмәлләр, үзенә күрә кибет тә була.

1942 елның 11 февралендә дәүләт комиссиясе әзер объектны кабул итеп ала. Кайбыч районы территориясендә танк үтә алмасын өчен эшләнгән каршылыклар да, окоплар да, блиндажлар да була. Барлыгы 392 күзәтү пункты, 98 ишерен ут ноктасы, 56 дзот, 419 землянка төзелә.

Фикер

Әминә ГАБИДУЛЛИНА,
окоп казуда катнашкан Иске Чәчкаб авылы кешесе:

– 1941 елда миңа 13 яшь иде. Әнием күкрәк баласын имезгәнгә, кеше саны булсын диптер инде, шәлгә төреп, мине дә окоплар янына илтеп куйдылар. Кәбестә кебек киенгән, селкенеп тә булмый иде. Кәйләләр, ломнар белән чукып, җирне өч метр тирәнлектә казып бардылар. Килгән кешеләрнең өсләрендә бик юка иде. Аякларында күн итекләр булганга, шыгырдап каттылар. Бигрәк тә студентларның хәле мөшкел булды. Авыл халкы аларга булдыра алганча ярдәм итәргә тырышты.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Иван ГУЩИН,
Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе:
– Без хәзер финиш сызыгында. Архивта эзләнү эшләренә керештек. Безне бүген кадастр документлары кызыксындыра. Объектның төгәл итеп чикләрен билгеләргә кирәк. Яз җитеп, карлар эрегәч, беренче чиратта Кайбыч территориясендәге 10 километрга сузылган урында фәнни-тикшеренү, эзләнү эшләре башланачак. Казан каймасы, һичшиксез, мәдәни объект буларак реестрга кертелергә тиеш.

АЧЫК БУЛСЫН КАПКАЛАР

2024 гаилә елы

Мамадышта яшәүче Фәридә һәм Илсур Әгъзамовларның гаиләсенә сокланмый мөмкин түгел. Алар бер-берләрен урау юллар аша эзләп таба. Берсе – Мамадыш районының бер ягындагы Усалидә, икенчесе икенче ягындагы Ямаш авылында туып-үсәнгәнме, тормыш корганчы шактый юллар үтә алар. Әмма күкләрдә язылган никах барыбер кавыштыра.

Еллар узгач, икесе дә беренче гаиләләреннән аерылгач очраша алар.

– Әтием Хуҗиәхмәт белән әнием Минненур 1946 елда Себергә чыгып китәләр. 1955 елга кадәр шунда яшиләр. Чит җирдә әти яңа шөгыль таба. Ул фотога төшерү белән мавыга башлый. Мамадышка кайткач, инде тәҗрибәле фотограф була. «Ул чакта дүрт бала инде туган, бишенчесе әнинең карынында була. Шулай итеп, гаиләбез туган якка кайтып кайтырга карар кыла, – дип искә ала Илсур абый. – Әти элеккеге КБО оешмасында эшли башлый, фотога төшерә. Ямаш авылына баргач, минем Фәридәмне дә матур итеп төшереп кайта әле. Ул чакта булачак киленен төшергәнен каян белсен инде әткәй? Әти фотога төшергәч, безнең балачак истәлекләргә бай булды. Әллә нинди фотоларыбыз бар».

Илсур абыйга 8 яшь чагында әнисе авырып китә. Табиблар яман чир таба. Минненур апа озак авырып ятмый. Сентябрьдә диагноз куела, декабрьдә исә үз туган көненә 11 баласын ятим итеп, ирен ялгыз калдырып, фани дөнья белән араны өзә. Хуҗиәхмәт абый, балаларына ятимлекне сиздермәс өчен, барысын да эшли, башка өйләнми дә. Балалар да дус, тату, бердәм булып үсәләр. Иң кечеләре Илсурга да моңаерга ирек бирмиләр. Елап утырмадым, ди ул үзе дә.

– Без бәләкәй чакларда бакчалар бик зур иде. Иртә яздан көзгә кадәр шунда эшлисең. Маллар күп, көш-корт җитәрлек. Эш белән көн узганын сизмисең дә. Ишле гаилә булгач, хәсрәтне җиңел күтәрдем. Әти яхшы кеше иде безнең. Үз сүзен әйтә белде. Безне кеше итәр өчен тырышты. Олы абыебыз, мәктәп бетергәч, табиблыкка укырга керде.

Аның артыннан без дә. Барыбыз да медицина хезмәткәрләре булдык, – ди Илсур абый. – Кубебез – теш табибы. Бергә җыелсак, хәлләр белешәбез дә, сүзебез һөнәребезгә күчә. «Консилиум»га, «пятиминутка»га әйләнә.

Фәридә апа да табиб һөнәрен сайлаган. Ул теш технигына укып чыккан. Язмыш алар гаиләсен дә сынауларсыз калдырмаган. Алар да 11 бала була. Ике игезәкләре Рәшит белән Рәшидә кечкенә чагында вафат була. Фәридә апаның үзенең дә Фәрит исемле игезәге 2015 елда дөнья куя.

– Безнең әни белән әти кинәт авырый башладылар. Мин дә Илсур кебек төпчек бала идем. Фәрит белән миңа 14 яшь булгач, әти-әнинең хәле авырайды. Алар бик бетәр кирәк. Әй эшләре миңа калды. Иртән торып, әти белән әнине ашатабыз да тиз генә маллар карап керәбез. Аннары мәктәпкә йөгерәбез. Мине укытучылар аңлый иде. Ике дәрес укыгач, тагын сорап кайтам. Әти белән әнине тәрбияләргә тырыштым, – дип сөйли ул. – Апа белән абыем, мине кызганып, авылга кире кайтты. Озак интекмәделәр, баштаган әти, аннан әни бакыйлыкка күчте. Туганнарым без мәктәпне тәмамлаганчы янибызда булдылар. Ятимлек ачысын сизмәдем дип булмый инде ул. Әтиәнисез калу җиңел булмады. Үзәк өзелде. Хәзер алты туганым гына исән.

Язмыш тәрләчә сынаса да, Илсур абый белән Фәридә апа, бергә кушылгач, бәхетле оя коралар. Ул чакта икесенә дә беренче никахтан кызлары була. Шунысы сөендерә: Илсур абый Фәридә апаның кызын үз исеменә яздырып куя. Бәхетләрен түгәрәк итеп, уртак уллары дөньяга килә.

– Мин әтигә бик рәхмәтле, – дип сүзгә кушыла Энже. – Ул мине бик яратып үстерде. Кирәк чакта кырыс та була белде. Теләсә кайда йөртмәде. Кичке клубларга йөрүемне теләмәде. Укырга кушты ул миңа. Әти дә, әни дә табиб булгач, миңа да шушы өлкәне сайларга киңәш иттеләр. Күп әйберләр әти өйрәтте. Ул әле элек укыганнарын белеп тора. Менделеев таблицасын яттан белә. Химия, физика, биология фәннәрен миңа ул укытты, дисәм дә була. Вакытын кызганмады, өйдә барысын да яхшылап аңлата иде, – ди Энже.

Мин язмышыма шулкадәр рәхмәтле. Медицина университетында укыганда Әгъзамова булуым белән горурланам идем. Нәкъ менә Илсур абый кызы булганыма сөенәм. Мин аңа бик рәхмәтле. Үзенеке итеп яратты. Инде хәзер миңа аннан да газиз кеше юк. Әти тырышлыгы белән ныклы белем алдым. Иремне дә укыганда очраттым. Әтиле булу минем язмышымны яхшы якка үзгәртте. Әле дә әтинең йөзенә кызыллык китермәсәм иде дип яшим.

Илсур абый белән Фәридә апа 2002 елда шәхси клиникаларын ачканнар. Гаиләләре белән шунда эшлиләр. Аларның улы белән килене дә, киявләре теш дәвалый. Кызлары әлегә декрет ялында.

– Бездә туганлык җепләре нык. Әтинең 11 туганы да исән сау. Алар шулкадәр дус-тату яши. Гел хәлләр белешеп, кунакларга йөрешәләр. Әниләр дә шулай. Бәйрәмнәрдә бергә җыела алмасак, җай табып, өйләренә барабыз, – ди Энҗе. – Баштә үзем бәхетле үссәм, хәзер балаларым өчен сөенәм. Әнемнең балалары да, әтинең кызынныклары да яратуда үсә. Әти белән әни безгә үрнәк. Аларга карап, гаилә җылысын сакларга өйрәнәбез. Әтиәниле өйгә кайту шундый рәхәт. Капкалары гел ачык торсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Авыл җаны

Нигез тартуы

Юл әллә кемнәр белән очраштыра, таныштыра. Бу юлы Чаллыдан моңа кадәр бер дә күрмәгән авылдашым белән кайттым. Мин мәктәпкә укырга кергәндә, авылдан зур дөньяга чыгып киткән дә ике ел элек авылга кайтып урнашкан.

Икебезнең дә Чаллы Башыннан икәнлеге ачыклангач, «Сурия кызы», – диюгә, әллә никадәр уртак сүзләр барлыкка килде. Ул мине «Сурия апаның шигырь язучы кызы» буларак белә дә булып чыкты. Яңа танышым Марат абыйның әтисе Габбас абый белән минем әни дистә еллар буе күрше Шахмай авылына йөреп укыттылар. Габбас абый – гөрнәдирдәй ир-егет, озын буйлы, нык гәүдәле; аның янәшәсендә биленнән бераз гына биегрәк әни белән Фирдәүсә апа атлыйлар (хәзер өчесе дә мәрхүмнәр инде). Баксаң, Габбас абый 1942 елда унсигез яшендә сугышка эләгеп, җиде елдан соң гына авылга кайткан икән. Потсдам конференциясендә сакта торган, Берия аның белән кул биреп күрешкән, сөйләшкән очрак та булган хәтта... Кыскасы, мин белмәгән әллә никадәр тарих бирәдә.

Усал идек без, ди Марат абый мәктәп тормышын искә алганда: «Шахмайга тулы бер класс булып бардык. Салкын көннәрдә әллә ничәшәр көн дәрес калдырабыз. Мәктәпкә дип чыгып китәбез дә авыл башындагы Хәйретдин өендә җыелышып кәрт сугабыз. Әни белеп алса (ул – үзебезнең авылда башлангыч сыйныфлар укытучысы), әтигә әйтә. Әти тыныч кеше иде, «Бөтенесе калганда, үзе генә бармас бит инде», – дип кенә куя. Шуннан линейкага чыгарып бастырып сүгәләр бит инде. «Йә, нишләтәбез боларны, Габбас?» – дип сорыйлар шунда басып торган әтидән. «Икенче юлы тазга утыртып сөйрәп барырбыз инде», – ди әти тыныч кына. «Орчык кадәр Сурия салкын дип тормаган бит, килгән», – дип өстәп куя. Миңа оят».

Чаллы Башында алар вакытында булмаган унберьеллык мәктәп безнең чорга туры килде, тик быелдан мәктәбебез бинасы ятим булып тора. Марат абый анда калган музей өчен борчылып йөри икән. Район башкарма комитетына да мөрәҗәгать итеп караганнар. Балалар бакчасында буш торган ике бүлмә бар, шунда урнаштырыйк, материаллар әрәм булып ятмасын; үз көнкүреш эше юк, тычкан-мазар тияр, таралып бетәр, дип куркалар. Әлегә уңай җавап ишетмәгәннәр. Шулай да бер балалар эшне ярты юлда калдырырга уйламый Марат абый (авылдашыбыз Ришат абый белән бергә ниятләгәннәр бу эшкә). Аны тыңлагач, миңа да оят булып китә. Минем бабама да килмәгән бит менә. Чынлап та безнең авылның мирасханәсе юк бит. Башка авыллар шикелле авыл тарихын китап итеп тә чыгармадык. Уйлыйм дисәң – уй, эшлим дисәң эш җитәрлек икән бирәдә.

Олыгая барган саен авылда яшәү җайлырак, дип саный Марат абый. Әле гаиләсе тулысынча авылга кайтып бетә алмаган үзе; тормыш иптәше оныкларны карашу өчен күбрәк Чаллыда яши. «Шәһәрдә эш белән вакыт үткәне сизелми ул, ә эшең булмаса, нишләп бетәрге анда?! – ди Марат абый. – Гел-гел телевизор карау да туйдыра; урамда бер-ике сәгать йөргәч, барыбер дүрт стена арасына кайтасы да җәмәгатең белән бер-береңә карашып утырасы. Авылда шөгыль күбрәк. Быел кыш буе кар көрәдек. Район үзәгенә бассейнга йөрим, җәяү йөрергә яратам. Ә яз җиткәч, вакытны җиткереп тә булмый», – ди. Балыкка йөри, гөмбәчегә әйләнгән, бройлер чебиләре үстерә, бакча... Бассейн, дигәннән. Акъярдан бер танышым килгән дә бассейнга: «Главага рәхмәт инде, главага рәхмәт», – дип такмаклый ди. Газетта җитәкчеләрне сүгәләр бит, рәхмәт укымыйлар. «Берүзәмә бер бассейн салдырды бит», – ди икән. Сәгать уннар тирәсендә килә дә берүзе коенып кайта икән.

Авылга кайткач, дингә дә якынаа төшкән Марат абый. Дин гыйлемен үзләштерә, мәчеткә намазга йөри башлаган. Яшьләрнең намазга килүенә шатлана. Ләкин аны да авылның киләчәге борчый. «Якынтирәдә күп кешегә эш булырлык берәр предприятие ачсалар иде», – ди. Фермер хуҗалыклары күбәеп, авылда яшьләр калдыру мөмкинлеге фаразлавым белән килешми. «Авылдагы фермерларны күзәтеп йөрим, таңнан төнгә кадәр эшлиләр, ял итәргә бер вакытлары да юк», – ди. Әнә тагын бер фермер гаиләсе эшен туктаткан икән. Гомер эшкә генә багышлана алмый шул.

«Буш йортлар күпме атауда?» – дип сорыйм. Алар яшәгән урам шулай атау булып аерылып тора. Юк икән, кышын буш торганнарына да язга таба кайтып йөри башлыйлар икән. Туган нигезне беркемнең дә таратып бетерәсе килми шул. Кендек каны тамган җир бит – үзенә тарта.

Лилия ФӘТТАХОВА


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Алдымда – кояш нуры

Салкыннар вәгъдә итсәләр дә, көннәрнең язга борылуы сизелә инде. Өйлә намазы җитүгә, энҗедәй кар бөртекләрен ялтыратып, кояш елмая, шуннан кәеф тә күтәрелеп китә. Бер көн шулай, бераз авырып торганлыктан, борчулы уйлар белән намазга баскач, тәрәзәдән кояш күренде һәм сәҗдә кыла торган урынга якты нур бөркелде. Шуңа бик сөендем. Кояш хәзер көннән-көн күбрәк яктырта, күңелне якты уйлар һәм өметләр били. Бу, Җир шарын көчле утлы кораллар балкышы түгел, кояш нуры мулрак яктыртсын иде, диган күңелгә уелырлык уй-теләкне көчәйтә. Нур балкышы – килечәккә өмет балкышы ул.

МӘДИНӘ апагыз

Идар Мөхәммәтҗанов

ЯЗГЫ КҮКРӘҮ

Карлар эреп, яз килүгә,
Чикләр узып, җир-су кичеп,
Кыр казлары кайткан кебек
Чылбыр-чылбыр тезелешеп,

Асылына кайта татар,
Кайта туган нигезенә.
Гасырларны кичә-кичә,
Кайта, димәк, үз-үзенә.

Тарта аны язгы күкрәү,
Сөю моңы – татлы тетрәү.
Әнкәйләрнең бишек җыры...
Әнкәй кебек, ил дә бирәү.

Туган илнең үзе кебек,
Туган тел дә бирәү генә.
Туганда ук иман нуры
Иңгән татар йөрәгенә.

Госман САДӘ

Ләйсәнебез булдыра

Соңгы елларда вакытлы матбугатны көнендә кулга алу көтелмәгән хәлгә әверелә башлаган иде шул. Менә Сәпәй авылы почта бүлекчәсендә дә елга якын арада ничәмә хезмәткәр алышынды, Азнакайдан да килеп карыйлар, тик күп булса ике ай чамасы йөриләр дә китеп баралар. Ниһаять, ундык диярлә дә булыр иде, әгәр дә монда эшләүчеләрнең үтенеч-гозерләренә чын-чынлап колак салынса, чөнки аларның хезмәт хакларына карасаң, аптырап каласың – көнен бирәдә үткәрүче япь-яшь хезмәткәрнең яшәеше өчен якын да килми, янәсе, ярты штатка гына җавап бирә. Никадәр зур авыл бит, тулы штат өчен шәһәр кадәр булу кирәк микәнни?! Хат ташучы – почтальон штатына бөтенләй дә якын килмәслек! Юкса атнага ничә мәртәбә ничә йөзләгән йортларны йөреп-гизеп чыгарга?! Ә бүген почта булеген ел ахырларыннан яшь кенә ханым Ләйсән Һадиева алып бара: көнкүрештәге исәп-хисап, пенсия бирү, башка түләүләрне башкара. Аның эшеннән һәркем канәгать. Мәдәният йортының бер башындагы өлеге бүлмәдә, күптән ремонт булмаса да, Ләйсән анда үзенчә зәвыклы күркәм күренеш кертергә тырышкан. Бер үк вакытта азык-төлек, башка төр товарлардан сәүдә киштәләре дә тутырылган – монысы хезмәт хакына бераз булса да өстәмә өчен, билгеле. «Болай миңа эшем бик ошый», – ди Ләйсән. Үз гаиләсе белән йорт салып яшиләр, ул Казан технология университетын һәм Әлмәт политехника техникумын тәмамлаган – бухгалтер-икътисадчы. Бәләкәче булганчы «Ак Барс банк»ында шул хезмәттә булган, ә декреттан соң авылдагы почтага килгән. Уңган-булганлыгы күренеп тора.

Ләйсән сеңлебез газета-журналларны, буранмай дип тормый, көнендә үк таратып чыга, рәхмәт аңа, чөнки күптән мондый хәлнең булганы юк иде. Әнә патриот шагыйребез Муса Җәлил дә «Хат ташучы» поэмасында Ләйсән кебек ялыкмасарны ничек хөрмәтләгән:

Тимербулат көн дә иртән
Торып китә районга,
«Кызыл Маяк» колхозына
Килгән хатны алырга.
Газет килә, журнал килә,
Ансы тагын бер кочак,
Һәм боларның барсына да
Егетебезнең күңеле шат.
Сумка тыгыз тулган булса,
Кайтуы да күңелле!..
Хат ташучы ударникның
Шатлыгы шул түгелме?

Әсгать СӘГЫТДИНОВ,
матбугат ветераны.
Азнакай районы

ХЕЗМӘТЕ БАРНЫҢ ХӨРМӘТЕ БАР

Әле күптән түгел генә 93 яшен тутырган Солтан ага Алиев: «Кеше гомере тау кебек», – дип әйтергә ярата. Олы мәгънәгә ия фикер бу: кеше тау итәгендә туа да, гомере буе өскә күтәрелеп, таугa менеп җиткәч, хозурланып як-ягына карана – дөнья уч төбендәге кебек. Гомер дәрес үтелгәнме, нинди гамәлләр кылынган? Шәхсән Солтан ага үзе гомер агышыннан бик канәгать, хәтер-хатирәләрен дә бөртекләп-бөртекләп хәтерендә яңарта...

Буа районының бай тарихлы Иске Тинчәле авылында дөньяга аваз салган ул. Урта белем алганнан соң, техникумда авыл хуҗалыгы белгечлеге һөнәрен үзләштергән. Совет армиясе сафларында хезмәт иткән, эшчәнлеген туган авылында башлаган. Югары белем алганнан соң, Спас, Дөбъяз, Нурлат якларында партия район комитетының икенче секретаре вазыйфаларында да булган, Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшкә инде зур тәҗрибә туплап килгән. Ул таләпчәнлеге, яңаша-тирәдәгеләргә игъмалылыгы, ярдәмчеллеге белән аерылып торган. Солтан абыйдан эш тәҗрибәсе алганнар, шөкер, исән-сау, алар аңа рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмый.

Рөстәм Зиннур улы Булатов та тумышы белән Иске Тинчәледән. Шулай ук авыл хуҗалыгы тармагында армый-талмый хезмәт куйган шәхес. 85 яшен тутырды. Әлеге мөхтәрәмнәребезнең шушы көннәрдә Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында кунак булды. Аларга министр Азат Җәббаров исеменнән котлау сүзләрен министр урынбасары Гөлүс Баязитов җиткерде, «Мактаулы ветеран» таныклыгы, истәлекле бүләкләр тапшырылды, республика агросәнәгате ветераннары советы рәисе Марс Алиев шулай ук җылы котлауларын җиткерде. Ветераннар исә олыгаеп барган көннәрендә онытмауларны, дустанә тәбрикләүләре, теләкләре өчен рәхмәтләрен әйттеләр, истәлеккә фотоларга да төштеләр. Фотолар министрлык музеена саклауга да куелачак.

Очрашу бик җылы, онытылмас булды, хәтер-хатирәләр яңарды, алар, һичшиксез, буыннан-буынга күчә барыр. Әйе, гомер яшәвең белән генә түгел, яшәвеңне тоюың белән дә кадерле.

Наил САБИРОВ,
Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
музей мөдире

Концерттан соң

ЧАНАЛЫ БӘЙГЕ

Эх, Пошалым чанасы ла,
Җәйләр җитсә – арбасы...
Җырлап үтсәң, сизелми дә
Өч Пошалым арасы.

... «Өч Пошалым – өч игезәк» җыры татар сәхнәсендә инде егерменче елын яңгырый. Сигезенче тапкыр тамашачыга тәкъдим ителгән «Пошалым чаналары» җыр фестивале кысасында кайтавазлана килә ул. Әлеге фестивальнең башында торган Урта Пошалым авылы егете, Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров шушы җыры белән авылын татар дөньясына танытты.

Сүзем – «Пошалым чаналары – 2024» турында. Өч көн буена дәвам иткән чара Урта Пошалым авылында фатыйхаланды. Рөстәм әлеге фестивальдә җиңүчеләр һәм «бәхетле» тамашачы (лотерея уенын истә тотып) өчен 50 Пошалым чанасын һәм 14 премия салынган конвертларны әзерләп куйган иде инде. Бу көнне Арча, Балтач, Әтнә талантларын көтеп алды шәрәфле жюри әгъзалары. Шулай итеп 53 конкурсант Урта Пошалым мәдәният йортында көч сынашырга шобага тартыштылар. Бу фестивальдә беренче катнашучы түгел, элеккеге конкурсларда дипломант, лауреат булган кайбер җырчыларны да танып алдым. Алдагыларыннан аермалы буларак, яңа сулыштагы җырлар, җиңелрәк әзерлек белән килгән талантларның бермә-бер күп булуы, араларында яшьләрнең өстенлек итүе күбрәк сөенердә.

«Пошалым чаналары» җыр фестивале кысасында күпме яшь талантларга канат куелган, күпмесе танылу алганнар, профессиональ сәхнәләргә күтәрелергә өлгергәннәре дә бар. Хәзерге көндә «Без – Пошалым чанасында үскәннәр» дип күкрәк кагучылар шактыйга җыйнала бит җыр сәхнәсен тотучылар арасында. Сүз уңаеннан, әлеге фестиваль барышында да танылган җырчылар – жюри әгъзалары ике җырчы егеткә Казанга музыкаль белем бирү йортына чакыру тәкъдиме ясадылар.

Автор фотосы

Жюри әгъзаларына җырчыларны алдагы этапка уздыру җиңел бирелмәде. Конкурсантлар арасында югары бәягә лаеклылар күп булганлыктан, аларның чыгышлары, вокал ягыннан дәрәҗәсен бәяләү вакыты шактый озакка сузылды. Кемнедер аерып алу кыен булганлыгы үзен сиздерep торды. Ни әйтсәң дә, киләсе турга бары 19 конкурсант кына үтәргә тиеш иде. Туй үпкәсе булмый дигәндәй, «иң-иң»нәр генә алдагы турга сайландылар.

Кичен икенче турга үтүчеләрдән Урта Пошалым мәдәният йортының залын шыгрым тутырган тамашачы «имтихан алды». Җырчыларның чыгышы көчле алкышларга күмелеп дәвам итте. Жюри әгъзалары да «буш кул» белән килмәгән булып чыктылар. Россиянең атказанган артисты Резедә Галимова, Татарстан Республикасының халык артисты, Башкортстанның атказанган артисты Рөстәм Асаев, Татарстан Республикасының атказанган артистлары Раяз Фасыйхов, Ринат Вәлиев, Закировлар (Рөстәм, Люция, Миләүшә) гаиләсе һәм башкалар музыкаль күчтәначләрен бүләк иттеләр. Урта Пошалым эстафетаны Арчага тапшырды.

Бирәдә дә фестивальдә катнашучыларны Арча мәдәният йорты тулы зал белән каршылады. Ә жюри әгъзаларының эше исә тагын да катлауланa төште. Фестивальнең шарты буенча финалга ундүрт җырчы гына юллама алачак икән. Алар инде Казан шәһәренең «Пирамида» күңел ачу үзәгендә җиңүче титулы өчен көрәшергә тиеш булалар. Шунысын билгеләп үтим: жюри әгъзалары шәхсән үземне гаделлекләре, объектив бәя бирүләре, профессиональлекләре белән соклandырдылар. Кыскасы, хөкемдарлык эшендә хилафлыкка юл куелмады.

Җыр фестиваленең финал өлеше, югарыда әйтеп узганымча, Казан шәһәрендә узды. Дүрт сәгатьтән артык барган тамаша залдагы берәүне дә битараф калдырмагандыр дип уйлыйм. Бу кичтә сәхнәгә тамашачы өчен ачыш булган 14 талант күтәрелде. Ышанычлы акларлык чыгыш ясадылар, афәрин! Аларның барысына да дипломнар, акчалата премияләр, бәйгенең олы истәлеге – Пошалым чанасы тапшырылды. «Пошалым чаналары – 2024» җыр фестиваленең җиңүчесе булып акапелла җыр башкарган Рәсүл Файрахманов танылды. Икенче-өченче урыннарны Булат Галиев белән Инсаф Габделбәров бүлештеләр.

20 «бәхетле» тамашачы да бу җыр бәйрәменнән рухи азык алу белән бергә Пошалым чанасында кайтып киттеләр.

Үзем дә Пошалым якларыннан яңа шигырь белән кайттым:

Эх, Пошалым, Пошалым,
Миңа бик нык ошадың.
Язгы көндәй, җанны назлый
Хәтта ап-ак кышларың.

Мин дә урап кайттым ул көн
Өч Пошалым юлларын.
Бәһаләп була кешене,
Күрсәң кайда туганын.

Эх, Пошалым, Пошалым,
Миңа шундый ошадың.
Чишмәләрең җырчы синең,
Үзгә җырлый кошларың.

Монда ту да, монда үс тә,
Моңлы булмыйча кара.
Мондый табигатьтә яшәү –
Үзе бер шифа, дәва.

Эх, Пошалым, Пошалым,
Миңа шундый ошадың.
Сихерләдең минем җанны,
Хисләремдә бушандым.

Кешеләрең алтын куллы,
Хәтта алтын йөрәкле.
Алтын табан чаналарың
Танытты бу төбәкне.

Вазыйх ФАТЫЙХОВ

Күчтәнәчләрне бутау яхшыга булды

Өлкәннәр көне алдыннан була бу хәл. Күптән лаеклы ялга чыккан Фәгыйлә апа фатир ишеген ачып җибәрсә, кулларына пакет тоткан ике кыз басып тора. Кызлар пакетны Фәгыйлә апага бирә дә бүләк алганлыкка имза куярга кушалар.

– Сез кайдан соң, кызлар? – дип сорый Фәгыйлә апа.

– Без – волонтерлар, сезгә элекке эш урыныгыздан бәйрәм бүләге китердек, – ди кызлар.

Артык төпченеп тормыйча, рәхмәтен әйтеп, ишекне ябып, аш бүлмәсенә уза апа.

– Ии, рәхмәт яугырлары, эшләгән җиремнән биргәннәрдер инде. Бер дә болай ук зурлаганнары юк иде, капчык тутырып күчтәнәч җибәргәннәр, – дип сөйләнә ул. – Пешергән өчпочмакларын да суынырга өлгермәгән, Ходай биргән күчтәнәч белән күршеләремне чәйгә чакырыйм әле, – дип, күршеләрен үзенә дәшә.

Тиз генә табын әзерли, күчтәнәчләрне өстәлгә тезә. Ул арада күршеләр килеп җитә, чәйнек тә кайнап чыга. Әминә апа алып кергән кайнар кыстыбыен табынга куя. Мәйшәкәр әби чакчак пешергән икән, шуны алып кергән. Өч күрше чәкердәшеп чәй эчәргә керешәләр. Әминә апа сөйләшеп утырганда, эш урыныннан бүләк килергә тиешлеген әйтеп куя. Фәгыйлә апа шулчак үзенә килгән бүләк белән мактанып ала, аптырап куя: аһ бит бүләкне ике көн алдан китерделәр ләбаса! Фәгыйлә апаның фатир номеры – 45, ә Әминә апаныкы – 54. Баксаң, теге кызлар, фатир номерларын бутап, Әминә апаның бүләген Фәгыйлә апага биргәннәр икән!

– Ярар, бик күңелле утырдык, заманча әйтсәк, күршеләр «корпоратив»ы ясадык. Аллаһы Тәгалә безгә шулай җыелып утырырга бер сәбәп насыйп иткән. Бер очрашу – үзе бер гомер. Дус, тату яшәүгә ни җитә, – дип әйтеп куя Әминә апа.

Җәүһәрия ШӘРИПОВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Хыял йөртү сәләте

Кечкенә вакытыгыз булган булса, сез дә беләсездер инде: сабый чакта без хыялланырга ярата торган идек. Ул хыяллар төрлечәрәк килеп чыккандыр инде: болытлардан югарырак йөзү дә, иң батыр, я иң матур кеше булу да калмагандыр. Бик зурлары да, бик кечкенәләре дә булгандыр. Минем туйганчы туңдырма ашарга хыялланган чаклар да булды. Бөтенесенекеннән дә матуррак кием турында да хыяллandым…

«Әни гармун алып бирсә ярар иде», – дип тә хыяллandым. Сәпит алып кайтсалар да, бик әйбәт булачак иде. Төрлеләре булды хыялларның. Кайберләре тормышка ашмыйча да калды, кайберләре Ходайның рәхмәтле чагына туры килде.

Ә хыялың тормышка ашса инде… Менә ул чагында дөньяда синнән дә бәхетлерәк кеше булмый. Хәтта аның тормышка ашуы бернинди могҗиза да түгел, ә үз тырышлыгың белән яуланган бер хәл икәнен аңласаң да. Менә мин бер җәйне бозау көтүе көттем дә шуның акчасына сәпит алып бирделәр. Гадәти бер хәл бит инде бу: эшлисең – хезмәт хакы түлиләр, шул акчага теләгәнеңне аласың. Барысы да гади генә. Ләкин ул чакта миннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр. Чөнки сәпит алу минем хыялым иде. Хыялның чынга әйләнүе ул һәрвакыт могҗиза сыман тоела. Тылсымлы көчләрнең синең хакта кайгыртуы, хөрмәт күрсәтүе шикеллерәк. Бәлки, чынлап та шулайрак берәр хикмәте бардыр да, чөнки миңа сәпит алмыйча: «Улым быелга сабыр итеп тор, зинһар, кышка кадәр мунчаны ныгытыйк та киләсе язда ук сиңа сәпит алырбыз», – дисәләр дә, мин каршы килмәгән булыр идем. Хәтта үпкәләмәс тә идемдер, чөнки бот буе булсам да, барысын да бераз чамалап торам бит инде. Ә алай булып чыкмады.

Ул чорда балалар гына түгел, өлкәннәр дә хыялга бирелә торган иде бугай. Кемдер яхшы ат асрарга тели, кемдер икешәр сыер тотарга… Безнең якта болар рөхсәт ителми иде. Рөхсәт булса да, кеше авырлык белән дөнья көтә, көче дә җитеп бетмәскә мөмкин. Ул авырлыкларның ясалмасы да җитәрлек була бит әле… Кемдер җиңел машина алырга хыяллана. Аны алу өчен акчаң булу гына җитми әле, әллә ничә ел чиратың җиткәнне көтәргә кирәк. Кемдер дуслары арасында гына: «Эх, берәр кечкенә тракторың булса икән», – дип көрсенә. Кемдер диңгез буенда яки чит илдә ял итеп кайтырга тели. Өлкәннәр бу. Бөтен җирдә чәчелеп-түгелеп йөрмәсә дә, һәр кешенең үзенә күрә бер хыялы була торган иде.

Бер карасаң, без бүген шулкадәр җиңел яшибез. Тормыш итү күпкә җайлырак та, рәхәтрәк тә. Авыл җирендә яшәү дә шәһәрдәгедән ким түгел. Газ кергән. Җәйге челләләрдә яки кышкы салкыннарда урманга барып, утын кисеп йөрисе түгел. Әле аның әзере дә хәзерге шикелле төймәгә басуга кабынып, өеңне җылыта башламый бит, күзеңне тырный-тырный таң тишегеннән чыгып, утын алып кереп, мичкә ягып җибәрергә кирәк. Мондый вактөяген эшкә чутлап торучы да юк инде ул чакта. Сараеңда коры утын булгач, сөенә-сөенә чыгасың. Су өйгә кергән хәзер. Салкыны да, җылысы да бар. Кранны борып кына җибәрәсе. Элек әллә күпме арадан мичкә белән алып кайта идек. Кер юу да машина ярдәмендә…

Бер сүз белән әйткәндә, бүген кешенең бөтен тормышы җитеш. Күңелсезләнерлек бер сәбәп тә юк. Тик без канәгатьлек кичерә алмыйбыз. Зарланабыз. Күңелдә шик тә, беркадәр тарсыну да бар бугай. Үз-үзебезгә бикләнү дә. Без үзебезнең рәхәт тормышыбызга канәгать булып яши белмибез. Әйе, бөтен нәрсә кыйммәт. Ләкин бар бит. Әйе, таң атса, акча сорап язылган хатлар килә. Кредитлар муеннан җыелган, ипотека… Ләкин түлибез бит. Хәтта колачыбыз җитмәслек булып тоелган бурычлардан да вакытында котылабыз. Нинди гамәлгә генә тотынсак та, очы очка ялганып бара… Канәгатьсезләнерлек бер нәрсә юк кебек.

Безнең канәгатьсезлекнең бер сәбәбе әнә шул хыяллану мөмкинлеге калмауда бугай ул. Без бүген нәрсә телибез – шуны эшли алабыз. Татлы ризык, затлы кием, яхшы аппаратура яки техника кирәкме – рәхим ит – кайчагында хәтта кибеткә дә чыгып торасы юк, өеңә китереп бирәләр. Диңгез буена яки чит илгә телисеңме: кайда телисең, нинди шартлар кирәк, нинди суммага төшсен… Барысы да әзер. Кайсы өлкәне генә алып карасаң да шулай. Хәтта төпкелдәге гади бер татар авылыннан океан артындагы илнең берәр урамыннан атлап барган кешеләрне күзәтү мөмкинлеге бар. Барысы да бар. Барысы да синең өчен. Бары тик түлә генә.

Түләү һәрвакыт мәҗбүри. Анысын беркайчан да шик астына куеп булмый. Ни генә эшләсәң дә, хәтта эшләмәсәң дә, түләргә туры килә. Салкында юка киенсәң, суык тия. Кичтән хәмер эчсәң, иртәнгә махмыры була. Кемнедер рәнҗетсәң, ул рәнҗеш булып кайта. Монысы – тормыш кануны. Элек тә шулай булган, хәзер дә беркая китми.

Хыялланыр мөмкинлекнең чикләнүе үзе дә, бәлки, ниндидер ялгышларыбыз өчен түләүдер. Кеше тормышының һәр өлкәсе, күңеленең һәр халәте мөһим бит инде. Олысы-кечесе юк. Тәннең бер өлеше шикелле бит инде алар да. Кайчагында уч төбенә сыярлык әгъзаның да әһәмияте дөнья бәясе була. Йөрәк, мәсәлән… Хыяллану сәләте дә, бәлки, әнә шундыйлардандыр…

ИЛДАР КЫЯМОВ:
«КЕМДЕР – БАЛЫККА, АУГА, Ә МИН АРХИВКА БАРЫРГА ЯРАТАМ»

Журналистлардан гына торган гаиләдә иң җиңеле һәм авыры нәрсә? Журналист тарихчы була аламы? Телеэфир вакытында нинди кызыклы хәлләргә юлыкканы бар? Танылган журналист, алып баручы Илдар КЫЯМОВ белән әңгәмәбез шул хакта.

:: Журналистикадан тыш, Казан консерваториясенең вокал бүлеген тәмамлагансыз. Төп һөнәрегез итеп журналистиканы сайлавыгызның сәбәбе нинди иде, Илдар абый?

– Балачактан ук район газетасында шигырьләрем басыла иде. Аннан соң классташлар белән булган хәлләр турында мәкаләләр дә язып карарга тәкъдим иттеләр. Соңрак «Ялкын», «Яшь ленинчы»га да язгаладым, ләкин язганнарым аларга үтми иде. Шулай итеп, шигырьләрне икенче планга куеп тордым, журналистика белән мавыгып киттем.

1988 елны журналистика бүлегенә укырга кердем, биш елдан соң кызыл диплом белән тәмамладым. Университетта укыган елларда Ирнис абый Рәхимуллин хорына йөрдем. Нәкъ менә анда җырга мәхәббәт туды. Шулай итеп, беренче белемемне алганнан соң, мин консерваториянең көндезге уку бүлегенә керергә булдым. Җырчы булмадым, чөнки моның кайбер кыенлыклары бар. Әйтик, көндәшлек көчле, күп акча һәм продюсер кирәк… Шуңа күрә мин алып баручы буларак танылып киттем. Әмма мин хәзер дә алтышар сәгатьлек банкетларда җырлыйм. Тавышым куелмаган булса, моны болай гына эшли алмас идем.

:: Телевидениегә килүегезгә егерме елдан артты. Нилəр үзгәрде?

– Мине телевидение дөньясына иң башта Миләүшә Сибгатуллина чакырды. Ул чакта «Таң җилләре аша» исемле котлаулар һәм рәхмәт хатларын укый торган тапшыру алып бара иде ул. 2002 елда өр-яңа канал ачылды, ул иртәнге дирекциядә эшли башлады һәм мине дә чакырып алды.

Нәрсә үзгәрде, дигәннән… Иң башта тапшыруның исеме үзгәрде. Иртәнге дүрттән торып, алтыда туры эфирга чыгып эшли идек. Аның сәламәтлеккә дә шактый зыяны булгандыр. Миләүшә белән озак еллар бергә алып баручы булып эшләдек, тапшыруыбызны бик яраталар иде. Ул – яхшы белгеч, күп нәрсәне мин Миләүшәдән өйрәндем. 2012 елдан әлеге тапшыру алдан яздыру (запись) белән чыга башлады һәм исеме «Манзара»га үзгәртелде. Бу исемне дә Миләүшә уйлап чыгарды. Бирелә төрле форматларны сынап карарга туры килде. Миңа калса, безнең тапшыруның тамашачысы гына үзгәрмәде: ул шундый ук таләпчән һәм милли эчтәлектәге контент сорый. Шуның өчен без һаман да милли кыйблабызны югалтмый эшлибез.

:: Эфир барышында кызык хәлләр дә булгалыйдыр?

– Андый хәлләр шактый күп булды. Бервакыт шарлар белән билетлар уйната идек. Яныбызда мәгариф министры утыра. Лототрон ябылып бетмәгән булган, шарлар идәнгә чәчелде. Ә без бит туры эфирда утырабыз. Министр, пышылдап: «Миңа сорау бирегез», – ди, ассистентлар һәм режиссер ярдәмчеләре идәндәге шарны чүплиләр, режиссер икенче планны күрсәтеп тора, ә без исә сорау бирәбез. Менә шулай итеп бу хәлдән чыккан идек.

Тагын бер вакыйга Фәнис Җиһанша интервью биргәндә булды. Көлә башлады бу. Туктый гына алмый бит! Ул өзек хәзер дә социаль челтәрләрдә йөри әле, халык та бу эфир турында шактый сөйләде.

:: Журналистлардан гына торган гаиләдә иң авыры нәрсә?

– Хатыным Мөршидә белән яшь вакыттан бергә эшләдек. Ул – барлык журналист баскычларын үтеп чыккан кеше. Кавышкач, бер-беребезне аңлап яшәдек. Аннан улыбыз Идел, актер булса да, читтән торып укып, безгә килеп кушылды. Хәзер инде Ихтыяр да шушы юнәлештә белем ала. Бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз, ярдәм итәбез. Гаиләбезнең социаль челтәрдә үз төркеме бар, анда гел язышып торабыз: мондый контент кирәк, бу сүзнең синонимы ничек, шундый сорау бар… Гадәттә мин яшьләрдән техник якны сорыйм, алар исә телгә бәйле сорауларын бирә.

:: Журналист һөнәре белән тормыш алып бару мөмкинме?

– Хәзерге көндә беркемгә дә җиңел түгел. Һөнәрең булу мөһим. Башка юнәлештә укып, журналистикага килгән кешеләр дә бар. Начар яшибез дип уйламыйм, чөнки хезмәт хакы түләнә, күбрәк эшләсәң, акчасын да яхшырак аласың. Тырышлык һәм иҗтиһад кирәк. Идел улым минем юлдан китте. Ул журналист кына түгел, алып баручы булып та эшли. Шуңа күрә үзен тәэмин итә алыр дип уйлыйм. Ихтыяр «Татар сүзе» конкурсында җиңү яулады, ул да нәфис сүздән ерак түгел. Әниләре – чын журналист, югалып кала торганнардан түгел. Акчаны аны ничек тә табарга була. «Журналистны аяклары ашата» дигән сүз дә бар, шуңа күрә тырышып эшләргә кирәк.

:: «Җырларымда – җирсүем» җыентыгыгызга «иптәш» көтелмиме?

– Әлеге шигырь китабын миңа илле яшьлегемә, иганәче табып, тормыш иптәшем Мөршидә белән улым Идел чыгарды. Ул миңа сюрприз булды.

Шигырьләрне язудан туктаганым юк, аларны күптәннән язам. Бер повесть чыгарасым килә. Хикәя һәм парчаларны да күптәннән язам. Афоризмнарым да шактый җыелды. Менә шуларны туплап, проза китабын чыгарсам, әйбәт булыр иде.

:: Туган авылыгыз тарихы турында китап язып, аны мәңгеләштердегез. Киләчәктә күңелегездәге «тарихчы»ның башка авыллар турында язу теләге юкмы?

– Ул китабым 2017 елда басылып чыкты. Аңарчы әле Чирмешән районының Әмир авылы турында язган идем. 912 битлек булды ул. Хәзер исә Мөршидәнең Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылы тарихын өйрәнәбез. Вакыт булганда архивларга йөрим, кешеләрдән истәлекләр язып алам.

Башка авыллар турында да еш сорыйлар, әмма минем заказга эшлисем килми. Өстән-өстән генә яза алмыйм. Шундый кешеләр дә бар: заказын, акчасын ала да, моннан-тегеннән материал караштырып, бер кешедән сораша, архивтан нәрсәдер таба да китап итеп бастырып бирә. Мин алай эшли алмыйм, намусым кушмый. Бер авыл турында язу дүрт-биш ел вакытны ала.

Аннан соң архивка бер кергән кешене аннан тиз генә чыгарып булмый. Бик комарлы эш ул. Азарт уяна: гел яңа мәгълүмат аласы, эшлисе килә башлый. Кемдер – балыкка, кемдер ауга йөри бит, ә мин архивка барырга яратам. Шаһинур Мостафин дигән оста язучы архивка баруны матур кыз белән күрешергә баруга тиңли иде. Чыннан да, бирегә син бик дулкынланып, әзерләнеп барасың. Шуңа күрә яшь язучы, журналистларга тәкъдимем шул: яшьтән үк үз авылыгыз һәм районыгыз турында ишеткән-күргәннәрегезне язып барыгыз, чөнки ул мәгълүмат югалырга мөмкин.

Әңгәмәдәш – Гөлназ ӘХМӘДИЕВА

Авыл фәлсәфәсе

ЯЗ ГЕЛ КӨТМӘГӘНДӘ КИЛӘ

Ничек инде көтмәгәндә килә? Һәр елны без бит язны үзгә көтү белән көтәбез. Кыш урталары үтеп, көннәр озыная башлауга урамда инде яз билгеләре эзли башлыйбыз дисезме? Анысы шулай. Күңел белән көтәбез дә, тик гамәлләребез белән барыбер әзер булып бетә алмыйбыз.

Аннан инде быел яз көтмәгәндә килде дигән булып, аклану эзлибез. Бер елны быел иртә килергә охшаган әле бу яз дип, беренче тамчылар күренүгә, әзерлек эшләрен башлыйбыз, өй кырларын кардан арчыйбыз, канаулар казыйбыз. Ә берничә көннән буран дулап, элеккесеннән дә күбрәк итеп кар өя, «марттта – шарт» дигән салкыннары булып, әлеге дымлы карлар көрәк «тешли» алмаслык булып бозланып ката. Бөтенесен өр-яңадан башлыйсы була. Хәтерлим әле: 1997 елның 7 апрелендә ул чакта Төмәндә яшәгән апам, эше төшеп, Казанга кайткач, бер кичкә авылга да кайтып килгән иде. Авылда инде язгы ташу. Ике авыл арасындагы болынлык тоташ су, дамба – су астында. Апам кичтән дә, иртән дә әлеге ике араны К-700 тракторына утырып чыкты. Ул китеп, бер-ике көн үтүгә, быелгы кышкы бураннардан көчле буран дулады. Авыл урамнарын ничә көн чистарттылар. Бөтен канауларны өр-яңадан казыйсы, бөтен территорияләрне өр-яңадан чистартасы булган иде. Мондый еллар да булып тора. Ә икенче елны быел яз тиз генә килергә охшамаган әле дибез… Тик табигатьнең үз кануны, аңа безнең фараз-юраулар бөтенләй дә ошамый, ул киресен эшли. Кинәт килгән язлар тагын да хәтәррәк. Син канау казымадың бит әле, өй кырларың чистартылмаган дип тормый, кар астыннан юлын табып, су үз «этлеге»н эшли. Уйламаганда өй асларына – бәрәңге базларына су керүләр дә булгалап тора. Әнә быел да галимнәр дә, фаразлаучылар да яз соңга калачак, карлар апрель азагында гына эреп бетәчәк дип ышандыра. Тик авыл агае сагая: юрауларның юш килмәгәнен күп күргән чөнки.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Инде авылларда күпләр язгы беренче әзерлек чараларын күрде, өй кырларын карлардан арчыды (дөрес, әлегә канаулар казымадык), ел да базларына су керүчеләр дә инде, бәрәңгеләрен капчыкларга тутырып, сәндерәләргә күтәрде. Быелгы карларның күплеге авыл агайларыннан башлап, республика җитәкчеләрен дә борчый икән, төрле очракка әзер тору, үзеңчә әзерлек чаралары күрү артыкка булмас, ди ул.

Елның шушы вакыты җитсә, авыл кешесе быел ташу булырмы икән дип тә хафалана башлый. Быелгыдай кар күп елны быел ташу каты булыр инде дип вәсвәсәләнә (быел исә туң юк, кар сулары сеңеп барыр дип тә өметләнә). Кар аз елны: «Быел юньләп кар да яумады, туң да юк, ташу булмас инде ул», – ди. Әмма еш кына фаразлар чынга ашмый: карлар эреп бетте дигәндә, шаулатып ташу ага, ястык калынлыгы карлар да җайлап юкка чыгып, юньләп ташу булмаган еллар да була. Хәтта гөрләвек суы акмый калган елларны да күрдек.

Шунысы тәгаен: авыл кешесе бер генә язны да тыныч күңел белән, борчылмыйча, хафаланмыйча каршыламый. Хәер, язны гынамыни?! Көзен яңгырларның җитәрлек яву-яумавыннан башлап, кышның салкынлыгы, карның аз-күп булуы, шуларга бәйле уҗымнар язмышы, язның ничек килүе, җәйләр буе күзләрнең күккә төбәлүе… Ни генә дисәк тә, табигать шартларына кул-аякларыбыз белән бәйләнгән шул без. Җирдә эшләп, башкача була да алмый торгандыр инде.

Бу көннәрдә авыл-районнарда кышны озату бәйрәмнәре үтә. Сагынып көтәбез дә сөенеп озатабыз шул кышларны. Ә быелгы кышны тиз генә онытмабыз кебек. Сәбәпләрен үзегез дә беләсез…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 231

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+